ФӘКЫЙРЬЛӘР КИМЕГӘН

Моңа нәрсә сәбәпче дә, саннар артында ни ята – «ВТ» шуны өйрәнде

> 5

КАРАП ЙӨРИСЕ

Татарстанда юлларны ремонтлау эшенә керештеләр

> 7

ЕЛАМАСЫН БАЛА!

Уенчык сайлаганда, нәрсәгә игътибар итәргә?

> 16

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 37 (29004) | Җомга | 17 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

100 ЯШЬЛЕК НУРАНИЯ ГАЗИЕВА:

«КЫЗЫМНЫ БИЕТӘМ ӘЛЕ»

Матур картлык! Барлык кешеләргә дә шулай итеп килсен иде ул. Казанда яшәүче Нурания әби белән сөйләшкәч, күңелдә әнә шундый уйлар туды. Аллаһы Тәгалә гомернең озынын гына биреп калмаган, зиһен дә, аң да, камил акыл да, сәламәтлек тә биргән. Үткән елларын да хәтерли, хәзергесен дә белә ул. 58 ел балаларга белем биргән укытучы!

> 17

Ишетми калмагыз

Быел Татарстанда 16 районда 22 терлек азыгы үзәге (тулы кыйммәтле азык, катнаш азык җитештерү өчен) төзеләчәк. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы матбугат хезмәте хәбәренә караганда, хәзерге вакытта 19 районда 39 шундый үзәк эшләп килә инде. Алар фермер хуҗалыкларын, агрофирмаларны гына түгел, шәхси ярдәмче хуҗалыкларны да тәэмин итә.
Быел Арча районында – берьюлы өч, Актаныш, Баулы, Кукмара һәм Тәтеш районнарында икешәр үзәк кору каралган. Алексеевск, Апас, Балык Бистәсе, Саба, Биектау һәм башка районнарда берәр комплекс төзеләчәк. Шул ук вакытта 24 районда әле бер генә терлек азыгы үзәге дә юк.

Татарстанда башлангыч сыйныф укучыларының өчтән беренең гәүдә авырлыгы тиешледән артык. Республикада 1–4 сыйныф укучылары арасында үткәрелгән сораштыру 100 баладан 32сенең симерүдән интегүен күрсәткән. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина әйтүенчә, артык авырлык проблемасы бигрәк тә башлангыч сыйныф укучылары арасында күзәтелә. Шуңа күрә мәктәпләрдә укучылар һәм ата-аналар белән дөрес туклану күнекмәләрен булдыру эшен алып барырга кирәк. Әлеге хәлдән чыгу өчен бик мөһим бу.
Социологик тикшеренү республикада 5–9 сыйныф укучылары арасында һәр 100 балага – 30, 10–11 сыйныф укучылары арасында һәр 100 балага 11 симерү очрагы туры килүен күрсәткән.

Яз язлыгын итә. Татарстанда кар эреп, дүрт күпер су астында калган. Бу хакта Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсендә хәбәр иткәннәр. Чәршәмбе көнне Буа районының Кыят һәм Килдураз авыллары, Нурлат районының Үрнәк авылы янындагы күперләрне су басуы турында билгеле булды. Биредә Зөя һәм Чирмешән елгалары ярларыннан чыккан. Күперләрдә су биеклеге 40 сантиметрга кадәр җиткән. Пәнҗешәмбе көнне исә Яңа Чишмә районының Архангел бистәсе янәшәсендә Шушма елгасы кар сулары белән тулып аккан. Нәтиҗәдә су күпер өстенә күтәрелгән. Коткаручылар әйтүенчә, авыл халкын эвакуацияләү куркынычы юк. Дүрт авылда да күперләрне уратып узу юллары бар. Әлеге җирлекләрдә язгы ташу ел да күзәтелә, дип тә тынычландырганнар.

Алдагы ял көннәрендә юеш кар-буранны 11 градуска кадәр суык алыштырачак.
Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, шимбә – 18 мартта һава температурасы көндез –1...+3, төнлә –4...+1 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә – барлык районнарда диярлек, көндез көнчыгыш районнарда юеш кар-буран көтелә. Якшәмбе – 19 мартта антициклон йогынтысында явым-төшем тукталачак. Көндез термометрның терекөмеш баганасы –1...+3 градус, ә төнлә –6...–11 градус күрсәтәчәк. Башлангыч фаразларга караганда, киләсе атна башында – 20 март көнне явым-төшем ихтималы аз. Көндез һава температурасы +1...–6, төнлә –3...–8 градус. Сишәмбе – 21 мартта җылы булачак: көндез +3...+8, төнлә 0...–5 градус.

КИЛӘЧӘК ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

3 меңнән артык катнашучы, 51 стартап. Казанда унҗиденче тапкыр Россия венчур форумы узды. Киләчәктә тормышка ашырырга мөмкин булган проектлар турында бүген сөйләшүгә корылган әлеге мәйданның абруен Татарстан башкаласына килгән кунаклар да югары бәяләде.

Форумның ачылыш тантанасында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Ул илебез венчур инвестицияләре базарының төп вакыйгасы булган әлеге чараның Казанда 2005 елдан бирле узуын искәртте.

– Казанда очрашып фикер алышу, күргәзмәләр оештыру өчен әлеге мәйдан бар. Без форумның быелгы эшен кызыклы һәм файдалы итәргә тырышачакбыз, – диде ул чарада катнашучыларга.

Аның сүзләрен Россия венчур инвестицияләү ассоциациясе башкарма директоры Альбина Никконен да куәтләде. Аның әйтүенчә, ел саен уткәрелүче форум мәйданы үзенең ни дәрәҗәдә әһәмиятле һәм мөһим булуын раслап күрсәтте инде.

– Форум күпсанлы инноваторлар һәм инвесторлар җәлеп итә. Күргәзмәдә тәкъдим ителгән һәр компаниягә – үз инвесторын табуын, ә һәр инвесторга җыеннан инновацияле технологияләр белән кайтып китүен телим, – диде Альбина Никконен.



tatarstan.ru

Быел форумда тышкы һәм эчке вазгыятькә бәйле рәвештә, базарны үстерүнең яңа юллары турында фикер алыштылар. Җыенда катнашучылар киләчәкне сайлый, дигән фикер белдерде «Сколково» фондының инновацияләр буенча өлкән вице-президенты Кирилл Каем.

– Бүген фикер алышкан проектлар киләсе биш-җиде елда без башкарачак эшләрнең нигезенә ятачак. Чөнки технологиягә ихтыяҗ арта гына. Әмма әлегә идея дәрәҗәсендә генә булган проектларга акча җәлеп итү көнүзәк мәсьәлә булып тора, – диде ул.

Быел форумда 3 меңнән артык кеше катнашырга теләк белдергән. Күргәзмәдә 51 стартап тәкъдим иттеләр. Аларны Рөстәм Миңнеханов та карады. Татарстан Рәисе фикеренчә, санкцияләр һәм тышкы чикләүләр безнең илдә венчур инвестицияләре темасына кызыксынуны киметмәде. Киресенчә, кайбер чит ил компанияләренең базардан китүе яңа катнашучыларга юл ачты. Бу хакта ул Россия венчур форумының пленар сессиясендә әйтте.

– Күргәзмәдә тәкъдим ителгән проектларның күбесе бик тормышчан һәм кирәкле. Форум тармакка бәйле мәсьәләләр буенча фикер алышырга мөмкинлек бирә. Без бу фикерләрне ил җитәкчелегенә җиткерергә тиеш. Мин дә бу эшкә кушылырга әзер, – диде Рөстәм Миңнеханов.

КАЛДЫКТАН – ЯГУЛЫК

Күчмә утырыш

Бик тырышсаң, пычрак судан да файда алып була икән. Моңарчы Казанның елгаларга агып яткан су калдыклары хәзер табыш китерә. Чистарту корылмаларына эләккән канализация суларыннан чыккан ләмнәрне киптереп, ягулык итеп куллана торган зарарсыз продукт ала башлаганнар. Бу хакта Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетының күчмә утырышында сөйләштеләр. Бирегә сүз су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү өлкәсендә коммуналь инфраструктураны модернизацияләү программасын гамәлгә ашыру турында барды.

Утырыш «Водоканал» унитар предприятиесендә узды. Аңарчы бер төркем депутатлар термомеханик эшкәртү системасы белән таныштылар. Мондый эш бары тик Татарстанда гына башкарыла икән.

– Әлеге проект 2021 елдан тормышка ашырыла башлады. Бу – республикада беренче объект. Аңа Россиядә дә тиңнәр юк. Әлеге система калдык суларны, ләм катламнарын термомеханик зарарсызландыра. Бу – яндыру түгел, ә киптерү. Башта бездә сынала, аннары инде аны башка төбәкләрдә дә куллана башлаячаклар, – ди «Водоканал» МУП директоры Андрей Егоров. – Яңа проект буенча чистарту корылмаларына эләккән канализация сулары тулысынча гранулаларга әйләндерелә һәм цемент заводларына ягулык итеп җибәрелә. Оешманың каты биоягулык һәм органик ашлама ясар өчен дә сертификатлары бар. Яңа барлыкка килгән ләм утырмаларын киптереп, аннан зарарсыз продукт ала башладык. Ә инде элеккеге калдыклардан җыелган ләм кырлары бүген кулланылмый. Аларны киптерәбез һәм рекультивациялибез.

Иртән кранны ачкач, су акса, барыбызга да рәхәт. Берәү дә аның каян, ничек акканы турында уйламый.

– Ә бит су белән тәэмин итү һәм су агызу – торак-коммуналь хуҗалык проблемаларының иң зурысы, – ди Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты рәисе Александр Тыгин. – Без суга бәйле эшләрнең асылына төшәргә һәм республика законнары ярдәмендә булган проблеманы хәл итәргә тиеш. Бар авырлык кулланучылар җилкәсенә төшмәсен өчен, моның чишелешен табарга кирәк. Әгәр бөтен нәрсәне акчага күчерсәк, су алтын бәясенә әйләнәчәк.

Андрей Егоров сүүткәргеч челтәрләрнең тузуына борчыла. Аларның күбесе 50 ел буена яңартылмаган.

– Казанда сүүткәргеч челтәрләрнең 70 проценты тузган. Узган ел суга бәйле 1,1 мең авария булды. Быелның өч аенда гына да өч урамда җир иңде. Челтәрләр таушалган. Аларын кичекмәстән алыштырырга кирәк, – диде ул.

Челтәрләрнең тузуыннан еш зарланалар. Белгечләр яңарту кирәклеген күптән әйтәләр инде. Татарстан Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык идарәсе башлыгы Айрат Галләмов, тузган челтәрләр буенча кайбер юнәлештә акрынлап эш башланды, ди.

– Соңгы 12 елда халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү республика программасы буенча 3 мең километр сүүткәргеч челтәр, 469 су башнясы һәм 474 артезиан скважинасы төзелде һәм реконструкцияләнде. Быел республиканың 45 районында 126 су белән тәэмин итү объектын төзү һәм капиталь ремонтлау планлаштырыла. Моның өчен дәүләттән 1,3 млрд сум акча биреләчәк, – ди ул.

Айрат Галләмов «Чиста су» программасына тукталды. Быел әлеге проект ярдәме белән 2 объект яңартылачак.

– «Иделне савыктыру» федераль проекты буенча пычрак сулар агуны өч тапкыр киметәчәкбез. Быел Россия Хөкүмәте тарафыннан коммуналь инфраструктураны модернизацияләүгә юнәлтелгән программа эшли башлады. Татарстан моңа бик теләп кушылды. Шул максатларда республикага 4,3 млрд сумнан артык акча бүлеп биреләчәк, республика бюджетыннан финанслауны исәпкә алып, гомуми сумма 8 млрд сумнан артык тәшкил итәчәк, – ди Айрат Галләмов.

Сан

Хәзерге вакытта республикада 2,4 меңнән артык үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасы файдаланыла. Сүүткәргеч челтәрләрнең озынлыгы 18,6 мең км чамасы, шулардан 6 мең км чамасы тузган һәм алмаштыру таләп итела. Татарстанда шулай ук 79 су чыгару системасы эшли. Канализация челтәрләренең озынлыгы 4,8 мең км тәшкил итә, шулардан 1,8 меңе тузган һәм яңарту таләп итела.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Районнарда ни хәлләр?

Алабуга

Мохтаҗларга ярдәм итүче «Приют человека» пункты актив эшли. Февраль аенда бирегә 2491 кеше кайнар аш белән тәэмин ителгән. 2022 елда монда барлыгы 21153 өлеш кайнар ризык таратылган һәм ике кешене эшкә урнаштырганнар. Хәзерге вакытта шәһәрдә тагын ике шундый урын әзерләнә. Берсен – 4 нче микрорайонда, ә икенчесен шәһәрнең түбән өлешендә урнаштырырга ниятлиләр.
(«Алабуга нуры»)

Буа

Буада яшәүче Гөлшат Мохтарова, чүплекләрдән, кешеләрдән борынгы әйберләр җыеп, үз карамагындагы бинаның бер бүлмәсен зур экспозициягә әверелдергән. Монда борынгы китап, җиз самавыр, тәңкә, унҗиденче гасыр үтүкләре, картина, чуен, комод, мамонт теше, хәтта моллюскларга кадәр бар. «Унҗиде ел буе җыйдым шуларны. Сорыштым, эзләндем. Аннары шушы борынгы әйберләрне алып кайткач, төннәр буе кырып юдым, сөрттем. Һынасызмы, шуннан ләззәт алам. Шушы экспонатлар арасында иң кадерлесе – әбиемнән калган унҗиденче гасыр Коръән китабы», – ди ул. Музейны ул балаларына мирас итәргә уйлый. Ишекләренең, бүгенге кебек, һәркем өчен дә ачык булуын да тели.
(«Байрак»)

Чүпрәле

Районның тармак технологияләре техникумында «Татар ашлары» пешекчелек эше буенча һөнәри осталык республика конкурсы узды. Аш-су осталыгы бәйгесендә хуҗалардан тыш, Азнакай, Апас, Буа һәм Алабуга, шулай ук Сарман районнары һөнәри уку йортлары студентлары да катнашты. Ярышлар нәтиҗәләре буенча Апас аграр көллияте студенты Әдилә Мөхәммәдиарова һәм Азнакай политехник техникумы студенты Руслан Вак – III дәрәҗә диплом, Алабуга политехник көллияте студенты Зарина Рәфыйкова һәм Сарман аграр көллияте студенты Наилә Хәсәншина – II дәрәҗә диплом, Чүпрәле тармак технологияләре техникумы студенты Айсылу Баһаутдинова һәм Буа ветеринария техникумы студенты Гөлинә Чумарина I дәрәҗә дипломга ия булды.
(«Туган як»)

Зәй

Түбән Биш мәктәбендә Татарстанның халык шагыйре, Габдулла Тукай премиясе лауреаты Рабит Батуллага багышланган музей ачылды. Музейда Рабит Батулланың шәхси әйберләре, китаплары, фотосурәтләре, кульязмалары, китап формасында эшләнгән газета төпләнмәләре тәкъдим ителгән. «Барыгызга да олы рәхмәтләремне җиткерәм. Музей эшләргә тиеш. Укучылар, кунаклар чакырып, музей белән таныштырырга кирәк. Минем дә бер тәкъдим бар. Һичшиксез, музейда Мөдәррис Әгъләмов һәм Наил Дунаевка (алар да шушы ук мәктәпне тәмамлаган) багышланган экспозиция ясалырга тиеш», – дип язды Рабит Батулла мәктәпнең «Мактаулы кунаклар» китабына.
(«Зәй офыклары»)

ТЫҢЛАП ТА ТОРАСЫ ЮК

Сүзенә дә, сурәтенә дә ышанмаска. Телефоннан шикле кеше шалтыратса, шушы кагыйдәне истә тотарга кирәк, ди белгечләр. Үзең турында шәхси мәгълүмат җиткерергә, акча күчерергә, банк картасы номерларын әйтергә ярамавын да кат-кат искәртә алар. Әмма алданучысы барыбер табыла.

Татарстан телефон аша алданулар иң күп теркәлгән төбәкләрнең беренче өчлегендә кала бирә. Республика халкы дистанцион рәвештә эш итүче мошенникларга атна саен 20 миллион сум акча күчерә. Рәмис Газыймов сүзләренә караганда, мондый юл белән кылынган җинаятьләрнең дүрттән берен банк картасыннан акча урлау, халыкны мәгълүмати технологияләр ярдәмендә алдау очраклары тәшкил итә.

– Быел ике айда телефон аша кылынган 2,5 меңнән артык җинаять теркәлде инде. Көненә шундый 30–35 гариза кабул итәбез. Мошенниклар аркасында республика халкы атна саен якынча 20 миллион сум акчасын югалта, – дип сөйләде ул журналистларга.

Рәмис Газыймов сүзләренә караганда, мошенниклар барыннан да бигрәк халыкны үзләрен банк хезмәткәре дип таныштырып алдый. Барлык җинаять очракларының 20 проценты нәкъ менә шуңа туры килә. Соңгы арада хәтта мессенджерлар аша да шалтырата башлаганнар. Әле бу көннәрдә генә Минзәләдә яшәүче бер кеше, шуларга ышанып, 300 мең сум акчасыннан колак каккан. Казандагы хастаханәләрнең берсендә бүлек мөдире булып эшләүче табиб та мошенникларга 740 мең сум акча күчергән.

– Фотода банк рәсеме чыккач, кеше ышана. Шуңа күрә үзен банк хезмәткәре дип таныштырган кешенең кушканнарын һич икеләнүсез эшли. Банк беркайчан да клиентларына мессенджер аша шалтыратмаячак. Шуңа күрә сөйләшеп тә торасы түгел, – ди Рәмис Газыймов.

Кайчак акчаны янга калдыру теләге дә харап итә. Зыян күрүчеләрнең 16 проценты онлайн рәвештә әйбер сатып алганда алдана икән. Кеше арзанлы товар өчен акча күчерә дә, сатучы шундук юкка чыга.

– Шуңа күрә әйберне ышанычлы маркетплейслардан гына сатып алырга кирәк. Узган ел шундый юл белән мех эшләнмәләре «сатып» яткан Пермь кешесе ирегеннән мәхрүм ителде. Ул Татарстанда яшәүче 14 гүзәл затны төп башына утырткан.

Рәмис Газыймов сүзләренә караганда, республика халкы бушлай белдерү сайтларында да еш алдана. Мошенниклар җибәргән шикле сылтама аша кереп, акчадан колак кага алар.

– Акчаны отышлы итеп инвестицияләргә тәкъдим итеп тә төп башына утырталар. Алар яратып кулланган алдау ысуллары арасында дүртенче урында тора бу. Соңгы арада республика халкына шул рәвешле 30 миллион сумлык матди зыян салынган. Бу очракта мошенник үзен финанс белгече дип таныштыра, акция, валютаны отышлы бәядән сатып алырга өнди, – ди ул.

«Туганыгыз юл һәлакәтенә эләкте», – дип шалтыратучыларга ышанучылар да күп. Бу очракта күбрәк пенсионерлар алдана. Узган ел алар, шундый сүзгә ышанып, 80 миллион сум чамасы акчасын югалткан.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Белдерү

Татарстан Республикасының «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә, 20 нче Электротехник бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын өстәмә сайлау максатында, 2023 елның 29 апреленнән 2023 елның 26 маена кадәргә чорда сайлау алды агитациясе үткәрү өчен, «Ватаным Татарстан» газетасында (массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык 1995 елның 21 июнендә бирелгән, № 430) басма мәйдан бирергә әзер булуы турында хәбәр итә.
Сайлау алды агитациясе үткәрү өчен бушлай бирелә торган басма мәйдан күләме һәр кандидатка 6,2 х 7,5 кв. см үлчәмендәге модульне тәшкил итә.
Басма мәйдан бирүгә җирәбә үткәрүнең анықланган вакыты, шулай ук агитация язмаларының календарь графигы турында өстәмә хәбәр ителәчәк.
Белешмәләр алу өчен телефоннар: 8 (843) 222-09-65, 222-09-70. Электрон почта адресы: info@vatantat.ru.

Татарстан Республикасының «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә, 20 нче Электротехник бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын өстәмә сайлау максатында, 2023 елның 29 апреленнән 2023 елның 26 маена кадәргә чорда сайлау алды агитациясе үткәрү өчен, «Ватаным Татарстан» газетасында (массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык 1995 елның 21 июнендә бирелгән, № 430) басма мәйдан бирергә әзер булуы турында хәбәр итә.
Сайлау алды агитациясе үткәрү өчен түләүле нигездә биреләчәк басма мәйдан күләме һәр кандидатка 6,2 х 7,5 кв. см үлчәмендәге модульне тәшкил итә.
Түләүле басма мәйдан бәясе А2 форматындагы чыгарылышта (беренче биттән тыш) – 1 кв. см өчен 95,04 сум, А3 форматындагы чыгарылышта (беренче полосадан тыш) 1 кв. см өчен 171,72 сум тәшкил итә.
Беренче полосада урнаштырган өчен – төп бәягә 20 процент, полосада урын сайлап алган өчен төп бәягә 10 процент өстәп түләнелә.
Газета редакциясе түләүле басма мәйданны бүлү буенча җирәбә үткәрү урыны һәм вакыты турында өстәмә хәбәр итәчәк.

Сәяси сәгать

АЛЬБЕРТ ШАКИРОВ: *«Без күрәсен кеше күрмәс»*

Без әле кая барабыз? Дөньяда ниләр бар? Бу сорауларга җавапны журналист, блогер Альберт ШАКИРОВ белән эзлибез.

:: Яңа көн туган саен Көнбатышта Россиягә карата санкцияләр турында уйланалар. Шул ук вакытта АКШта берничә банк банкротлыкка чыкты. Ерак, әлбәттә, әмма бүгенге шартларда бу вакыйгалар Чүти авылындагы Галия түтигә нәрсәсе белән куркыныч?

– АКШтагы югары технологияләргә инвестицияләр ясау, стартаплар белән шөгыльләнүче бер банкның банкротлыкка чыгуыннан гына, шуны күперткәннән генә бөтен дөньяда кризис башланачак дигән сүз түгел әле. Бәлки, башка банкларны да шундый язмыш көтәдер. «Бөек депрессия» чорына керәбез дигән сүзләр дә еш ишетелә чөнки. Миңа калса, бу күбрәк сәяси сүз уйнату кебек тоела. Чөнки АКШта Президент сайлавына әзерлекне күптән башладылар. Вашингтондагы хәзерге администрация эшләрне шундый хәлгә җиткерде, алга таба тагын да начаррак булачак, дигән сүзләр шуңа да бәйле. Безнең яктагыларга да: «Күрәсезме, кирәк җиргә кысылулары, санкцияләр кертүләре үзләрен үк ыштансыз калдыра», – дип сөйләргә бер сәбәп булды. Сүз дә юк, безнең финанс системасы алардан күпмедер дәрәҗәдә читләште. Беренчедән, шул сәбәп, икенчедән, санкцияләрнең, чикләр ябылуның сизелерлек йогынтысыннан тагын да зуррак үзгәреш булмас дип уйлыйм.

:: Узган атнада ковидның 3 еллыгын билгеләп уздык. Сабак алдыкмы пандемиядән?

– Мондый вакыйгалар тиз килеп чыга да тиз онытыла шул. Хәзер инде паниканың эзе калмады, иялләштек. Игътибар итегез әле: хәтта белгечләр дә вакцинация турында зурлап сөйләшми. Халык элеккеге тормышына әйләнеп кайтты. Шуңа күрә сабак алдык, нәрсәгәдер өйрәндек, дип әйтерлек түгел. Сүз дә юк, инфекция хастаханәләре төзү, аларның эшчәнлеген җайга салу, лабораторияләр кору, тиз арада вакциналар уйлап табу кебек зур эшләр башкарылды. Ул мәсьәләдә алга китеш булды. Ләкин нәтиҗә ясарга да, иркенәеп китәргә дә иртәрәк әле. Иң куркынычы – ковид белән авырганнан соң килеп чыккан синдромнар. Кемнән генә сорама, шуннан зарлана. Анысын белгечләр бик яхшылап өйрәнер дип өметләнәм.

:: Соңгы арада белгечләр авызыннан «курку пандемиясе» дигән гыйбарә дә еш ишетелә. Кеше үзен үзе куркытып яши, хәтта булмаганны да, бар, дип сөйли, диләр. Син нәрсәдән куркасың?

– «Без күрәсен кеше күрмәс», – дигән фәлсәфә бар бит инде халыкта. Мин дә шуның буенча яшим. Нәрсәнедер курку белән көтеп яшәү аның булуына караганда күбрәк бетерә, күбрәк кимерә кешене. Әлбәттә, алдыңны-артыңны карап яшисең. Кирәк урында запас әзерлисең, кирәк урында сәламәтлекне алдан кайгыртасың. Барысына әзер булып торуның иң яхшы юлы – онытылып эшләү. Халыкта курку хисе бар. Әле менә бүген бик популяр саналган җырчы белән сөйләштек. Пандемиядән соң тамашачының үз-үзен тотышында үзгәреш бар, ди ул да. Концертка килгәч, туарылып китеп бәйрәм итү элек урыны-урыны белән генә булса, хәзер бөтен җирдә шул күренеш, ди. Кешенең басылып-басылып, пружина кебек кысылуы, аннары иркенәеп китүе дип аңлыйм моны.

:: Киләчәк турында уйлаганда артка да борылып карау кирәк. Илдә «Алдынгылар хәрәкәте» җәелә башлады, мәгарифтә үзгәрешләр көтелә. Әмма бүгенге яшь буынга элеккеге тәҗрибә килешерме?

– Элек тә, хәзер дә балалар һәм яшьләр белән эшләү алымнары бер инде ул. Яңадан велосипед уйлап чыгарасы юк. Шуңа күрә бу эшләрне совет чорына кире кайту димәс идем. «Алдынгылар хәрәкәте»нең структурасын карый башласаң, аның юнәлешләре дә, максат һәм бурычлары да, эшләү тәртибе дә башкачарак. «Без – пионерлар» дип байрак күтәреп, барабан кагу турында гына сүз бармый бит. Әйтик, кызыксынуларына карап, балаларны төрле юнәлешләрдә үстерү, киләчәктә шулар буенча кертеп җибәрү күздә тотыла. Мәктәп бусагасыннан башлап зур тормышка әзерләү инде бу. Яхшы булганны, начармы – совет системасының бүгенге мәгариф өлкәсенә алырдай яклары бик күп. Бигрәк тә тәрбия мәсьәләсендә. Чөнки анда беркайчан да үзгәрми торган кыйммәтләр һәм алымнар бар. Мәктәптә әләм күтәрүләр кертелде бит ел башыннан. Кабул итмәүчеләр булды. Миңа калса, начар ягы юк. Дәүләт символларына да ихтирамы булмаган кешедән киләчәктә нәрсә көтәргә?

:: Бу көннәрдә «Ак барс» Гагарин Кубогы өчен көрәшә. Нәрсә генә дисәк тә, спорт ул очко һәм медальләр генә түгел. Түшенә Татарстан гербы рәсеме ясалган уенчыларның җиңүе халыкның кәефен күтәрә, республикасы белән горурлану хисен арттырамы?

– Шәхсән миңа бернинди йогынтысы юк. Карамыйм да, кызыксынмыйм да, борчылмыйм да. Нәтиҗәләрне йә таныш-белеш сөйләшкәннән, йә хәбәрләрдән күреп беләм. Әмма җиңүләр икән, күңел күтәрелә. Минем кебек кызыксынмаган кешегә дә шундый йогынтысы бар икән, даими карап баручыларга, әлбәттә, нык кагыла. Спортның берләштерә торган көче бар. Бөтен кешене бер дулкынга җыя ул. Без моны Казанда дөнья чемпионатлары узганда бик ачык күрдек.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Язучы сүзе

ЭЛЕКТРОН АКЧА

Марат КӘБИРОВ

Соңгы чорда акча тотып караган юк икән. Ярлыклыктан гына түгел бу. Илләр имин булмаса да, зарланып яшәсәк тә, җитәкчеләрне эттән алып этәгә салып сүксәк тә, бер нәрсә бәхәссез – бүгенге кешенең өсте бөтен, тамагы тук. Ләкин акча белән сирәк эш итәбез икән: бөтен нәрсә банк карталары белән хәл ителә. Шулай җайлырак та. Элек ничек иде… Кибеткә барасың, кесәңнән бөгәрләнеп беткән йөзлекләр алып түлисең, шуннан сдача көтеп торасың. Ул сдача я булмый, я бик вак акчалар белән бирелә. Ташлап китәргә ярамый инде, чалбар кесәңә тыгып куясың. Ә ул атлаган саен шалтыр-шолтыр килеп бара. Шуннан берәр танышың килеп чыга да күрешергә кулын суза:

– Сәлам! Нәрсә шалтыратып йөрисең?

Кулыңа арурак акча керсә, аны кая тыгарга да белгән юк, кайсы кесәңә салсаң да төшеп калыр сыман. Әледән-әле капшап карыйсың тегене, бер урыннан икенчесенә күчереп куясың. Бәла инде, кыскасы. Әле шундыйрак сәер ир-атлар да була торган иде: хатынына йөз мең кайтарып тоттыра да соңыннан тәмәкегә дип тегеннән йөз сум сорап йөри. Ә хатыны бирми. Дөрес эшли, көлтә белән биргәнсең икән, бөртекләп сорамаска кирәк.

Электрон акчаның хасил булуы, карталарга күчү эшне күпкә җиңеләйтте. Төшеп калыр, югалыр, диясе юк. Заначкага дип яшереп куясы юк. Кесә тутырып, тиеннәр төяп йөрисе юк. Авыл җирендә бигрәк рәхәт инде, сатучылары таныш, теләгән чагыңда чыгып, товар җыясың да соңыннан акча күчерәсең. Сүзе генә ни тора әле аның – акча күчерү! Элек бик зур бизнесменнар, җитәкчеләр генә «акча күчерербез» дип сөйләшә торган иде. Хәзер барыбыз да акча күчерәбез. Шәһәрдәге уңайлыкларын әйтеп тә торасы түгел. Банк карталары – хәзинә. Хәттә төшереп калдырсаң я урлатсаң да, бөтен акчаңнан колак какмыйсың, мизгелендә үк хезмәт күрсәтүне туктатып торырга була. Ә кредит-фәлән ала башласаң, хәттә банкка да барып торасы юк, картаңа күчерәләр. Могҗиза!

Шулай сокланып йөргән вакытта төрле матбугат чараларында акчаны цифрлаштыру турында сөйли башладылар. Кәгазь вариантын бөтенләй юкка чыгарып, электронга гына калдыру турында сүз бара инде. Бетсен, әйдә! Электрон акча күпкә җайлырак бит… Мин, бу мәгълүматларга өстен-өстен генә карап, шундыйрак фикер йөрттем…

Бер мәлне бер дуска кунакка киттем. Хәзер бөтен җирдә дә кибетләр бай бит инде, күчтәнәч-фәләнен баргач кына алырмын дип, кулны селтәп кенә юлландым. Барсам, тегеләрнең авылында телефон да тотмый, интернет та кермәгән икән. Кибетләрендә кәгазь акча белән генә хисаплашалар. Кире район үзәгенә җилдердем. Анда кибетләрдә әйбер алырга була. Картадагы акчаны кәгазьгә әйләндерергә теләп, банкомат эзли башладым. Гади эш түгел икән, монда андый банк турында ишеткәннәре дә юк. Берни дә килеп чыкмады. Мин, үзебезнең шәһәрдә бай гына булып йөргән адәм, бу төбәктә бер тиен акчасыз хәерче хәлендә калдым…

Монысы – икенче очрак инде: Казан метросына төшкән урында теләнеп утырган бер әбигә хәер биреп китим дип, кесәмә тыгылдым. Тегә өмет тулы күзләрен төбәде, ычкындырмый. Ә минем кесәдә карта гына. Кешене юкка ымсындырып ары киттем: «Әбекәй, телефон номерыңны әйт әле, сәдака бирәм», – дип әйтеп булмый бит.

Болары – минем күзгә күренгәне генә әле. Тик шул ике күренеш тә чүт кенә нәтиҗә ясарга җитә. Чикли сине электрон акча. Беренчедән, ул синең кайсы төбәкләргә сәяхәт итү мөмкинлегеңне үз карамагына алырга мөмкин, икенчедән, ул синең күңел халәтеңә, тойгыларыңа, теләкләреңә, хәттә йолаларыңа да хуҗа була ала. Бу – әлбәттә, бераз шаянрак нәтиҗә. Бераз шаянрак. Һәм бераз нәтиҗә.

Шушы хәлләрне бер танышыма сөйләгән идем, ул кул селтәп кенә куйды: «Синеке ерунда гына икән, мин автобус белән бер шәһәргә барганда бәдрәфкә керә алмыйча интектем. Егерме сум сорыйлар, ә кесәдә бер тиен дә наличка юк. Тиешле җиргә җиткәнче утырган урында биеп барырга туры килде».

БАЗАР БИРЕГЕЗ, БАЗАР

КАПИТАЛИЗМ ҖИМЕРЕЛГӘНДӘ

Сишәмбе көнне атаклы Америка олигархларыннан берсе, 32,6 миллиард доллар капиталга ия булган Кен Гриффин дигән әфәнде Силикон үзәне банкы (Silicon Valley Bank) җимерелү уңаеннан Financial Timesка биргән интервьюда: «Америка капитализмы күз алдында җимерелә», – дигән белдерү ясады. Гафу итегез, тагын искә алмыйча булмый, бу юлларның авторы андый белдерүне 2008 елның көзендә үк ясаган һәм «Америка кояшы батармы?» дигән язмада сәбәпләрен дә китергән: «Финанс пирамидасының ишелүе, әхлакый яктан таркалу…» – дип санап киткән иде.

Silicon Valley Bank һәм, гомумән, процент капиталында үскән барлык банклар да – төбенә төшеп карасаң, финанс пирамидалары алар. Кертем ияләре һәм кредит алучылар саны үскәндә генә яши алалар. Икенче төрле әйткәндә, финанс базары киңәйгәндә, банклар яши, базар тарайса, мәтәлчек атып, упкынга очалар. Глобаль капитализм, тулаем алганда, шундый принципка корылган: аның үсеше өчен базарның туктаусыз киңәюе кирәк. Гадирәк итеп аңлатып карыйк әйдә. Банк ачтык, ди. Безгә ике нәрсә кирәк булачак: а) акча; б) ул акчаны бездән процентлар белән алырга риза булучылар. Соңгыларының алганны арттырып кайтарып бирүе дә таләп ителә, билгеле. Акча табуның берничә юлы бар: а) халыктан депозитка җыябыз; б) бизнес бездә хисап ача; в) Үзәк банктан кредит алабыз; г) кыйммәтле кәгазьләр уйлап табабыз һәм аларны сатабыз…

Бу юлларны файдалану өчен «ышаныч» дигән нәрсә кирәк. Шул булса, клиентлар базары тәэмин ителә. Ышаныч бетсә, клиентлар акчаларын кире таләп итә башлыйлар һәм базар җимерелә. Банкларның төпкә очуының беренче классик ысулы бу һәм Силикон үзәне банкы нәкъ шул ысул белән җимерелде дә: абруйлы әфәнделәр социаль челтәрләрдә Silicon Valley Bankның хәле мөшкел булуы турында берничә генә пост элделәр һәм «коллапс» дип атала торган нәрсә килеп тә җитте. Дөньяның төрле почмакларында ул банкта хисап тотучылар һәм аның акцияләрен сатып алучылар хәзер үзләренең югалтуларын саный. Гарәп илләрендә дә, Израильдә дә, Европада да, Кытайда һәм Һиндстанда да бар алар. Базарның киңлегенә игътибар итегез дип китерәм географияне. Банк яшәсен өчен, кредит алучыларның да киң базары кирәк, алар гына җитмәсә, банклар спекуляция белән шөгыльләнәләр: кыйммәтле кәгазьләр сатып алалар. Фәнни телдә инвестиция дип атала ул, чынлыкта спекуляция генә инде, чөнки кыйммәтле кәгазьләрнең бәясе күпертелә, куык ясала. Куык тишелү белән, банклар бөләләр. Монысы – банк түнтәрелешенең икенче ысулы. Силикон үзәне банкы да депозитларны түләү өчен кыйммәтле кәгазьләрен сатып котылмакчы булды, әмма кәгазьләрнең бәясе төшү сәбәпле оттырды. Өстәмә үз акцияләрен сатуга куеп та яшәп калмакчы булды. Монысын базар бөтенләй кабул итмәде, банкның ышанычсызлыгына дәлил буларак карады һәм паника көчәйде генә. Югыйсә, акцияләрен сата алса, вакытлыча котылачак иде. Базар таба алмады.

Банкларның базарны яулауларының үз ысуллары бар. Бу очракта безгә ул кирәк түгел. Американың Федераль резерв системасы һәм АКШ Финанс министрлыгы бу атна башында капитализмның төп принципларының берсенең «эченә типтеләр»: янган банкка акча салучы һәркемгә (депозиты иминиятләштерелмәгән булса да) барлык акчасын кайтарып бирергә вәгъдә иттеләр. Шулай эшләмәсәләр, чылбыр реакциясе башланып, барлык банклар да егыла башлаячак иде. Депозитларга түләү өчен тагын акча басарга туры киләчәк, тагын инфляция үсә инде. Монысы банкларга түгел, акчага ышанычны бетерә. Акчага ышаныч бетү – системаның һәлакәте дигән сүз. 1991 елда СССРда яшәп караган кешеләр моны хәтерлиләрдер әле. Соңгы вакытларда доллар бәясенең төшүе, дәүләтләрнең милли валюталар белән исәп-хисап ясый башлаулары күз алдында. Базарга Кытай юане, рус сумы, төрек лирасы, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре дирһәме чыгарга омтыла. Валюталарның күплеге базарның тараюына китерәчәк һәм бер дә юньлегә түгел бу.

Финанс базарын куеп торып, реаль җитештерү базарына килик әле. Авыл хуҗалыгының хәсрәтенә әйләнгән мул уңыш темасын тагын бер күтәреп карыйк. 2020 һәм 2022 елларда Татарстанда гектардан уртача 33,5–35 центнер бөртекләләр уңышы алынды, тулаем җыем 5 миллион 200 мең – 5 миллион 213 мең тоннадан артып китте. 2021 елда уңыш гектардан 14,9 центнер, тулаем җыем 2 миллион 353 мең тонна гына булган. Һәм… 248812,5 миллион сумлык авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерелгән. Ике тапкырдан күбрәк уңыш алуга карамастан, 2020 елда 264328,7 миллион сумлык продукция җитештерелгән, ягъни 2021 елда уңыш кимрәк булу җитештерелгән продукциянең акчалата күләменә зур йогынты ясамаган. Башка елларда да шулайрак ул. Уңыш күпме генә булмасын, сумнарга күчергәч, күләм бер чама. Аңлыйбыз инде: уңыш күп булганда, бәя төшә, аз булганда, күтәрелә дә үлчәү тәлинкәсен тигезли. Уңыш күп булганда, табыш күбрәк булырга тиеш, ди аек акыл. Әмма табыш өчен уңышның муллыгы гына җитми, базарның киңлеге дә кирәк. Сата алмыйсың икән, күп җитештерү матди зыян гына китерә. Татарстан фермерларын коткаруның бер генә юлы бар бүген: кичекмәстән яңа амбарлар төзеп, ашлыкны дәүләт резервларына сатып алу. Шул эшләнмәсә, алдагы сезонда без чәчүлек җирләренең кыскаруын, уңышының кискен кимүен һәм бәяләрнең берничә тапкыр үсүен күзәтәчәкбез. Акча ни өчен банкирларга гына бирелергә тиеш ди әле? Россия финанс хакимиятләре, мәсәлән, Америка банкы түнтәрелү уңаеннан, бездә андый хәл булмаячак, чөнки банкларга акча биреләчәк, дигән рухтагы белдерү ясады. Банкларны коткарырга акча бар икән, әйдәгез, авыл хуҗалыгын да коткарыйк, ул стратегик яктан хәзер күпкә әһәмиятлерәк.

Үткән атнада Япониядә бер рәсми белдерү яңгырады. Моңарчы Украинага корал белән ярдәм итмәгән Кисиде хөкүмәте Киевка корал озатырга ниятли. Япония законнары буенча Кояш чыгышы иленнән читкә корал экспортлау тыела. Тик бу законның шулай ук «эченә тибәргә» җыеналар. Япониянең Оборона сәнәгать комплексы сәясәтчеләргә басым ясый. Чөнки, диләр алар, бу корал җитештерүне рентабельле итү өчен кирәк. Хәзерге вакытта илдә җитештерелгән кораллар чамасыз кыйммәт, чөнки эчке базар ихтыяҗларына гына эшләгәндә үзкыйммәт зур чыга. Япон хәрбиләре беренче чиратта кичекмәстән Украинага реактив залп уты ачу җайланмалары MLRSларны (Америка HIMARSларының төрдәше) озатуны куәтлиләр. Мәсьәләнең хәрби ягын куеп торып, икътисадый аспектын гына карыйк. Нинди генә товар җитештермә, технологиядән тыш, базар кирәк. Бүген бөтен дөньяда хәрби бюджетлар үстерелә һәм оборона сәнәгать комплексларына заказлар арттырыла. Тармак вәкилләре моңа шатланып кулларын уа, чөнки табыш күктән яуган кебек ява. Украина конфликты һәм борынлап килгән башка конфликтлар зур базар вәгъдә итәләр. Әмма базар даими булсын өчен, даими хәрби конфликтлар да кирәк булачак. Финанс базарындагы, чимал һәм товар базарындагы вазгыять безне акрынлап Бөтендөнья сугышы дигән катастрофага этәрә. Базарларны яңача бүлешү теләге көчәя.

Россиядә бер ел инде үзебезнеке җитештерик дип талпыналар. Ниндидер яңа нәрсә җитештерү – мөмкин эш ул. Сәләтле интеллектуаллар да, борчаны дагалый торган осталар да илдә беркайчан бетми. Инвестицияләр дә табылачак, әмма чылбырның соңгы буыны – базардан башка берни дә барып чыкмаячак. Кул арбасы ясап, эчке базар белән канәгатьләнергә була, әмма, гафу итегез, автомобиль өчен ул тар.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ХАЛЫК КЕСӘСЕ

Россиядә фәкыйрьләр саны кимегән. Росстатның яңа мәгълүматлары шул хакта сөйли. Фәкыйрьләр саны 10,5 процентка калган. 15,3 млн россияле дигән сүз бу. Әлеге күрсәткеч яңа Россия тарихында иң түбәне булып санала. Бер ел элек китерелгән саннар зуррак: фәкыйрьлек дәрәҗәсе 11 процент, ягъни 16 млн кеше иде.

Ярлыларның кимүе нинди сәбәпләргә бәйле? Яшәү минимумына чыдап та яшәп буламы? Халык кесәсенә «кереп», акча санап карадык. Язмада саннар күп очраячак, шуңа күрә алдан ук кисәтеп куюны дөрес дип саныйбыз.

Сәбәпләр

Ярлы дип кем санала соң? Бу – билгеләнгән яшәү минимумыннан түбән керемле кеше.

Россия Президентының илкүләм үсеш максатлары турында Указы нигезендә, 2030 елга фәкыйрьлек дәрәҗәсе 6,5 процентка кадәр төшәргә тиеш. Шуңа күрә күрсәткечләргә чигенергә мөмкинлек бар әле. Ә хәзерге уңай үзгәрешләргә нәрсә сәбәпче соң?

Социаль түләүләр. Росстат мәгълүматлары буенча, 2022 ел азагына халыкның керем өлешендә социаль түләүләр 20,7 процентны тәшкил иткән.

Ярлылыкны киметүгә балалы гаиләләргә ярдәм дә үз өлешен керткән. 2023 елның 1 гыйнварына караган мәгълүмат буенча, өч миллионнан артык аз керемле гаиләгә (шул гаиләләрдә 3–7 яшьлек 4,2 млн бала яши) айлык матди ярдәм күрсәтелгән. Узган елның апреленнән 8–17 яшьлек балалар өчен кертелгән бердәм пособие исә 3,7 млн гаиләгә кагылган. Бу гаиләләрдә 5,5 млн бала тәрбияләнә. Бюджеттан әлеге максатлар өчен 1 трлн сум акча бүлеп бирелгән.

Моннан тыш 2022 елда пенсияләрне индексацияләү дә булды. Бу да фәкыйрьлекне киметүгә азмы-күпме йогынты ясаган. Хөкүмәттән халыкка өстәмә рәвештә 400 млрд сум акча бүлеп бирелде, шул рәвешле уртача пенсия күләме 19,3 мең сумга кадәр күтәрелде.

Керем күләме. Җан башына туры килә торган уртача керем үсеше дә саннарга тәэсир иткән. Росстат мәгълүматлары буенча, 2022 елда бу күрсәткеч, 12,4 процентка үсеп, 45,3 мең сум тәшкил итте. Керем өлешендә хезмәт хакы 57,2 процентны били.

Фәкыйрьләр санының кимүенә хезмәт базарындагы хәл дә тәэсир итә. 2022 елның уртасыннан Россиядә эшсезлек күрсәткечләре рекордлы дәрәҗәдә түбән саклана. Хәзер ул 3,6 процент тәшкил итә.

Шул ук вакытта 2022 елда халыкның реаль матди кереме – 1,4 процентка, бөтен мәҗбүри түләүләрдән соң калган акчалата кереме исә 1 процентка кимегән. Сәбәпләр арасында инфляция күрсәткече, COVID-19 пандемиясеннән соң тернәкләнү чоры да бар.

Казан (Идел буе) федераль университетының кеше ресурслары белән идарә итү кафедрасы ассистенты, икътисадчы Артем Халиков аз керемлеләр саны кимүгә тәэсир иткән башка факторларны да атады.

– Һичшиксез, аз керемлеләр кимүгә социаль түләүләр дә тәэсир итә. Андый түләүләр дигәндә, ишле гаиләләрне генә күзалларга кирәкми. Шул ук мобилизацияләнүчеләрнең гаиләләренә булышу да булды. Аларның күп өлеше – аз керемлеләр категориясеннән. Тагын бер сәбәп – МРОТ (хезмәт хакының минималь күләме), пенсия артты. Кешеләр күбрәк хезмәт хакы ала башлады. Бюджет өлкәсендә эшләүчеләр сизгәндер дип уйлыйм. Ана капиталы да ярдәмгә килә. Аны куллану мөмкинлеге хәзер киңрәк. Ләкин Росстат мәгълүматларына гына таянып яшисе түгел. Кеше үзе чынбарлыкка карап анализ ясарга тиеш. Росстат бар нәрсәне уртача ала. Төрле эштә эшләүчеләр бар. Әйтик, җитәкче 100 мең сум алса, урам себерүче – 10 мең. Барысын да бер калыпка салып, яхшы яши башладык дип булмый. Аңлашыла инде, һөнәргә никадәр күбрәк ихтыяҗ булса, аның хезмәт хакы да югары дигән сүз. Ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар. Ихтыяҗ булган профессияләр исемлеге дә билгеле. Бик үк популяр булмаган хезмәтләр өлкәсе бар. Әйтик, китереп бирү хезмәте, онлайн эшләүчеләрнең хәле хәзер аеруча әйбәт. Дәүләт биргән түләүләр, әлбәттә, яхшы. Әмма хәзерге бәяләр белән чагыштырып караганда, болар да җитмәс кебек тоела. Яшәү минимумына гына яшәп булмый, – диде белгеч.

Җан асрау күпмегә чыга?

Ярлыларны ничек барлый соң Росстат? Элегрәк кереме яшәү минимумыннан түбәнрәк булган кешеләр санына таяналар иде. 2021 елдан яшәү минимумын һәм минималь хезмәт хакын исәпләүнең яңа моделе кулланыла. Исәпләү нигезендә азык-төлек кәрзине түгел, ә җан башына уртача керем һәм уртача хезмәт хакы ята. 2021 елдан башлап яшәү минимумы күләме ел саен билгеләнә, ә элегрәк квартал саен иде.

Хөкүмәт яшәү минимумына яшәргә дип кушкан икән, яшәп карыйк инде. «ВТ» хәбәрчесе үз мисалында исәп-хисап башкарып карады. Сүз гаиләсе (ире яки хатыны, балалары), йорт хайваннары, автомобиле булмаган кеше турында бара. Янчыгыннан күпме акча чыга икән?

Мәҗбүри чыгымнар	Өстәмә чыгымнар
Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү ~ 2,5–4 мең сум	Маникюр ясату ~ 1100 сум
Азык-төлек ~ 5000 сум	Каш ясату ~ 600 сум
Кредит ~ 4000 сум	Андый-мондый киргәге чыкса, дип калдырган акча ~ 2000 сум
Юлга тотыла торган акча ~ 2100 сум	Кино, театр, күргәзмә, концерт ише күңел ачу чараларына ~ 1500 сум
Мобиль элемтә хезмәте өчен түләү ~ 300 сум	

Татарстан буенча яшәү минимумы 13319 сум тәшкил итә. Бу – хезмәткә яраклы кешеләр өчен. Пенсионерларга – 10508 сум, балаларга – 11852 сум. Россия күләмендә исә яшәү минимумы түбәндәгечә: эшкә яраклы халык өлешенә 15669 сум тия, пенсионерларга – 12363 сум, балаларга исә 13944 сум тиеш. Таблицадагы саннарга карап, нәтиҗә чыгаруны укучы хөкеменә калдырабыз.

Шунысын да әйтергә кирәк: бу исемлеккә фатир өчен түләү кертелмәде. Чөнки бу чыгымны «ВТ» хәбәрчесе үзе генә күтәрми. Азык-төлек өлешендә ит, сөт, йомырка, кайбер яшелчәләр дә исәпкә алынмый, чөнки хәбәрче аларны авылдан алып килә. Аларын өстәсәң, билгеле ки, дәүләттән бирелгән «минимум»га яшәү мөмкин түгел. Хәер, юк, мөмкин түгел димим. Акчаны бик кысып тоткан очракта, очын-очка ялгау дәрәҗәсенә җитеп яшәү мөмкиндер. Анысын инде яшәү дип атарга булса, әлбәттә... «Минимум» арткан чакта интернет, мобиль элемтә, торак-коммуналь хезмәтләр, азык-төлек бәясе дә өскә үрмәләде бит. Аннан, тормыш булгач, төрле хәлләргә дә юлыгасың. Имгәнмичә, авырмыйча да тормыйсың. Сәламәтлекне кайгырту – үзе бер «минимум»лык! Аена бер булса да кунакка, мәҗлескә дә чакырмыйча калмыйлар. Анда да буш кул белән килеп булмый. Көндәлектәге вак-төякләрне санамыйсың да инде: әле кием-салымны кыскартасы, әле химик чистартуга алып барасы, әле лампочка алмаштырасы...

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Россия буенча кайбер товарларга һәм хезмәтләргә уртача бәяләр *(сумнарда)*

Исем	6 февраль	9 февраль	6 март
Сыер ите, кг	483,62	486,97	487,52
Сарык ите, кг	553,62	544,14	547,40
Сосиска, сарделька, кг	468,36	463,56	465,17
Туңдырылган балык, кг	207,16	209,01	210,29
Май, кг	836,07	835,27	834,12
Үсемлек мае, л	132,00	131,20	130,67
Маргарин, кг	240,50	242,46	242,03
Пастеризацияләнгән сөт, л	72,98	74,62	74,70
Каймак, кг	280,61	282,32	282,94
Тавык йомыркасы, 10 данә	81,78	81,49	84,12
Дөге, кг	110,15	109,48	109,18
Вермишель, кг	106,92	108,73	107,71
Бәрәңге, кг	32,30	34,53	34,61
Кишер, кг	39,34	44,45	46,19
Суган, кг	33,81	44,37	54,05
Кер юу порошогы, кг	204,86	206,09	205,31
Шырпы, кап	3,04	3,11	3,16
Сабын, 100 г	58,57	58,71	58,70
Ашханәдә, кафеда (оешмадагы ашханәдән тыш) төшке аш, 1 кешегә	421,05	426,12	428,18
Бәдрәф кәгазе, рулон	22,58	23,00	22,94
Чәч кистерү (ир-ат)	522,18	519,85	523,81
Чәч кистерү (хатын-кыз)	702,68	706,15	709,48
Җиһаз машинаны юдыру	529,21	553,69	555,60
Йорт хайваннары азыгы, кг	318,34	320,93	321,88

АКЧАНЫ ЯНГА КАЛДЫРАМ, ДИСӘҢ...

1. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен ташламалардан файдаланырга, кибетләрдәге акцияләрне карап барырга.

2. Күңел ачуларга сак карарга. Акча таләп ителми торган чараларга йөрергә (андыйлар еш очрый), фильм-спектакльләрне телевизордан карарга.

3. Интернеттан баш тартырга. Дөресрәге, ай саен фәлән сумма ала торган тарифлардан. Акчаны минутлап ала торганына күчәргә.

4. Җәяү йөрергә. Эш һәм яшәү урыны арасы әллә ни ерак булмаса, бу мөмкинлек сезгә туры килә.

5. Түләүле хезмәтләргә алмаш эзләргә. Кайчагында «сарафанлы радио» ярдәмгә килә. Чәч кистерү, каш-тырнак ясату өчен, еш кына модельләр кирәк була. Андый чакка туры килсәгез, билгеле бер сумма акчагыз янга калачак. Бәлки, алтын куллы туганыгыз, дустыгыз да бардыр.

СЕЗГӘ ЯШӘРГӘ НИЧӘ СУМ АКЧА КИРӘК? *(аена)*



- 10–15 мең **9%**
- 20–30 мең.......................**34%**
- 50 меңнән күбрәк...........**39%**
- 100 меңнән күбрәк **18%**

(«ВКонтакте»дагы төркемдәге сораштыруда 307 кеше катнашты)

«ТАТАРЛАРНЫ ӨРКЕТЕП ҖИҢЕП БУЛМЫЙ»

АВЫЛ ЭШМӘКӘРЛӘРЕН НИ БОРЧЫЙ?

Казанга без сөенеп киләбез, чөнки сездән үрнәк алабыз, берләшәбез һәм тәҗрибә уртаклашабыз. XI Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыенында катнашкан һәр милләттәшебезнең ихластан әйткән сүзләре бу. Россиянең 47 төбәгеннән килгән татар эшмәкәрен нәрсә куандыра һәм нәрсә борчый? Без шул хакта белештек.

Проблемалар уртак

Башкортстан эшмәкәре Ирек Бакиров кибетләр тота, камыр ризыклары пешерә торган цехлары да бар.

– Соңгы ике елда халыкның сатып алу мөмкинлеге шактый кимеде, – диде ул бизнестагы авырлыклар турында сораша башлагач. – Кибет тотучы кешеләр булырак, моны бик нык сизәбез. Бәяләр артып торгач, ул товар сатудан кергән керемнән түгел, ә халыкның алган товар күләменнән күренә. Бу безне борчымый калмый, әлбәттә. Эшмәкәрлектә икенче зур проблема – кадрлар кытлыгы. Дәүләт Думасына армиягә 21 яше тулганнарны гына алу тәкъдиме белән закон проекты кертелде, дип яздылар. Мин моны бик яхшы булыр иде, дип уйлыйм. Чөнки ул яшькә кадәр егет кеше профессия алып өлгерергә тиеш.

Ирек Бакиров тагын бер теләген җиткерде. Аның фикеренчә, дәүләт шәхси хуҗалыкларда үстерелә, җитештерелә торган продукцияне сату-сатып алу белән кызыксынырга тиеш.

– Алар ит, сөт, яшелчә бик күп җитештерә. Хөкүмәт әлеге продукцияне сатуны дөрес итеп оештырсын иде. Авыл халкының тырышлыгы, теләге бар, ә мөмкинлеге юк. Иң үзәккә тигәне шул. Элек әзерләү конторалары бар иде, ник әле шуларны кабаттан торгызмаска? – диде ул.

Тагын бер эшмәкәр – кунакханәләр, кибетләр тотучы Бакир Акжигитов (Пенза өлкәсе) җыенга төгәл максат белән килүен әйтте.

– Татар эшмәкәрләренең иң зур проблемасы – Россиянең барлык төбәкләрендә дә Татарстан вәкилләре булмау. Егетләр башка эшмәкәрләр белән кем аша элемтәгә керәсен белми. Чөнки алар белән кулга-кул тотынып эшләүчеләр юк. Безнең эшмәкәрләр министрлыкларга да, түрәләргә дә кирәкми. Минем менә шул фикеремне җиткерәсем килә, – диде ул.

Шуннан соң без Россия төбәкләрендә җитештерелгән продукция һәм халык кәсебе товарлары күргәзмә-ярминкәсенә үздык. Биредә гадәттәгечә берничә юнәлеш тәкъдим ителгән иде: милли киемнәр, татар брендлары, авыл хуҗалыгы продукциясе, милли ашлар, сувенирлар һәм башкалар.

Күргәзмәдә Мордовия фермеры Азат Алмакаев үз хуҗалыгында җитештергән сөт ризыкларын тәкъдим итте.

– Терлекләрне грант акчасына сатып алган идек. Сөтне үзебез эшкәртәбез. Ниндидер зур проблемалар бар дип әйтә алмыйм. Барысы да яхшы, киләчәктә эшебезне тагын да зурайтырга, хуҗалыкны киңәйтергә телибез. Без, Мордовия фермерлары, Татарстан егетләре белән аралашып, киңәшләшеп яшибез. Үз юнәлешебездә эш алымнарында, ярдәм чараларында ниндидер зур аерма күрмим, – диде ул.

Аның янәшәсендә ат итеннән казылык, колбаса, сосискалар сатучы фермер продукцияне сатуда авырлыклар барлыгын әйтте.

Мордовиядән килгән тагын бер эшмәкәр – «Карпай» фирмасы җитәкчесе Айса Баймашев белән дә аралашып алдык. Әлеге оешма Белозерье татар авылында көнбагыш үстереп, орлыкларын Европага сатуы белән данлыклы. Үзгәреш җилләре аларның бизнесында да эзсез узмаган.

– Санкцияләр кертелүгә, авырлыклар башланды, – диде эшмәкәр. – Хәзер без товарны башта Белоруссиягә китерәбез, шуннан соң аларны Латвия машиналарына төяп, башка җиргә алып китәләр. Экспорт күләме 50 процентка төште. Сорау шулай ук булса да, логистика белән авырлыклар эшне тоткарлый. Элек без ике атнада барып җитә идек, хәзер юлда айга якын вакыт уза. Ә көнбагыш – бик нәзберек товар.

Түбән Новгород өлкәсенең Сафаҗәй авылы фермерлары Әлфия һәм Рамил Сафиулловлар казылыкны биш төрле ат ите кушып ясый. Җыенда яңа сатып алучылар табабыз, Казаннан кайткач та, казылык сорап шалтыратучылар бар, диделәр.

Районнарда күп йөрсәк тә, моңа кадәр никтер Татарстанда киндер үстереп, аннан май ясаучы эшмәкәр турында ишеткәнебез булмаган. Чирмешәндә исә бу эш белән әле ике ел элек кенә шөгыльләнә башлаганнар. Динар Хәлиуллинның күргәзмәдә беренче тапкыр катнашуы икән.

– Өч ел элек без 100 гектар мәйданда киндер үстерә башладык. Аннан май ясау идеясен ике ел элек тормышка ашырдык. Киндер маеның организмга файдасы зур. Шулай ук скраблар да ясыйбыз. Эшчәнлегебезне тагын да җәелдереп, киндер сабакларын эшкәртеп, тукыма ясар өчен җепселләр әзерләмәкче булабыз, – диде ул.

Эшмәкәр әйтүенчә, республика өчен бу – яңа бизнес. Үзләре исә белемне төрле җирләргә барып карап алган, өйрәнгән.

– Сораучылар күп. Сатуда авырлыклар бар, дип әйтеп булмый. Киресенчә, җитештереп өлгермибез. Гомумән алганда, киндер базары киң үсеш алган. Шуңа күрә без бу күргәзмәгә үзебезне күрсәтергә, танытырга, партнерлар табарга килдек. Төзелеш, текстиль тармагында безнең чималны эшкәртергә әзер булган эшмәкәрләр белән танышу хыялы да бар. Кызганыч, эш башлаганда программалар барлыгын белеп бетермәгәнбез. Белешкән булсак, аларны файдаланган булыр идек. Яңа бизнеста мәгълүмат, белем җитмәү – һәр фермерны, эшмәкәрне борчый торган мәсьәлә.

Соңгы елларда эшмәкәрлеккә татар яшьләре килмәвенең сәбәбе, бәлки, шулдыр да. Милли киемнәр брендын булдырган Айгөл Сөнгатуллина фикеренчә, җыенны бары тик татар эшкуар яшьләренә генә багышласалар да, артык булмас иде.

– Бизнеска килүче яшьләрнең проблемалары бөтенләй башка. Мин, мәсәлән, үзем рәхәтләнеп моңа кадәрге икътисадый кризисларны узган тәҗрибәле эшмәкәрнең киңәшләрен тыңлар идем, – диде ул.

«Татар югалыр дигән куркыныч юк»

Җыен, елдагыча, өч көн барды. Аның кысасында эшмәкәрләр Чувашия Республикасының Шыгырдан, Тукай һәм Урмай авылларында булдылар, татар авылларының комплекслы үсеше белән таныштылар һәм татар авыл эшмәкәрләренең хуҗалыкларын карадылар. Моннан тыш, җыен кысасында Россия Герое, пилот Дамир Йосыповның язмышына бәйле «На солнце, вдоль рядов кукурузы» фильмы премьерасы күрсәтелде.

Өченче көнне исә кунаклар «Корстон» күңел ачу комплексына җыелды. Татар авыллары эшмәкәрләре җыены елдан-ел бизнес, үсеш турында сөйләшүдән бигрәк, төрле җирләргә сибелгән татарның булдыклы уллары һәм кызларының җылы бер очрашу, аралашу мәйданы булуын дәлилли. Һәм, әлбәттә, татарлык белән горурлану хисләре. Шуңа күрә, бәлки, пленар утырыш башында дүрт көн элек кенә вафат булган, Башкортстанның данлыклы фермеры, татар токымлы атлар үрчетү белән шөгыльләнгән Хәсән Идиятуллинга багышланган видеоролик аеруча нык тәэсирләндергәндер. Аның атлары белән бергә берничә тапкыр утарын яндырмакчы булалар. Тик ул берни каршында да бирешми, киресенчә, тагын да үҗәтләнебрәк эшләвен дәвам иттерә. Аның: «Татарларны өркетеп җиңеп булмый. Алар белән бары тик килешергә, аларны яратырга гына була», – дип әйткән сүзләре соңгы әманәт (нәсыйхәт) буларак яңгырады.

Утырыш барышында Премьер-министр урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразыев җыенга Россиянең 47 төбәгеннән, 5 чит илдән һәм Татарстаннан 500дән артык кече бизнес вәкилләре һәм фермер хуҗалыклары җитәкчеләре җыелуын искә төшерде. Чыгыш ясаучылар үзләренең эшчәнлекләре, уңышлары, социаль һәм мәдәни тормышка керткән өлешләре турында сөйләде.

Әйтик, Азнакай эшмәкәре, җитештерү кооперативы идарә рәисе Булат Шәфигуллин 2019 елда Санкт-Петербургта «Татар утары» сәүдә мәйданын оештырып җибәргән иде. Эшмәкәр әйтүенчә, әлеге мәйданчык – Россиянең төньяк башкаласында Татарстанның 50дән артык җитештерүчесе продукцияләрен халыкка тәкъдим итә торган бердәнбер урын. Быел әлеге проектны тагын өч мәйданда ачарга теләүләрен дә әйтте. Ул утырышта катнашкан эшмәкәрләрне биредә үз товарларын сатарга чакырды.

– Меңләгән кеше «Татар утары»на продукция алырга гына түгел, ә милләттәшләребез белән аралашырга дип тә килә. Ул – шәһәр халкы һәм килгән кунаклар өчен Татарстанның заманча яшәше белән танышу урыны да. Киләчәктә «Татар утары»н туристлык маршрутына кертергә хыялланабыз, – диде ул.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, эшмәкәрләрне сәламләп:

– Бер күрешү – бер гомер. 11 ел буенча очрашып торабыз, аралашабыз, уңай фикерләрне башкаларга җиткерергә тырышабыз. Глобальләшү чорында бергә булырга кирәк. Зур үсешләр булганын күрәбез: татар халкы, теле, дине югалыр дигән бернинди дә куркыныч юк. Татар халкы Россия илендә үзен данлыклы халык итеп күрсәтә, – диде.

Шуннан соң ул эшмәкәрләргә, бизнес алып барган өчен генә түгел, ә татарлыкларын саклап калулары, йолаларны һәм традицияләрне буыннан-буынга тапшырулары өчен рәхмәт әйтте.

– Без татар эшмәкәрләреннән үрнәк алабыз, – диде Татарстан Рәисе. – Барыгыз да үз көчегез белән эшне алып барасыз, татарлыкны сакларга тырышасыз, гореф-гадәтләрне киләчәк буыннарга җиткерәсез. Киләчәктә дә шундый булыгыз.

Зәһрә САДЫЙКОВА

Фикер

Ирек БАКИРОВ, Башкортстан эшмәкәре:
– Татар авылы эшмәкәрләре җыены безнең өчен – бер-беребез белән танышу, тәҗрибә уртаклашу, аралашу мәйданы. Быел үзебез белән берничә яшь эшмәкәрне алып килдек. Чувашиядән алар шаккатып кайтты. Менә ичмасам эшләп тә, яшәп тә күрсәтә алар! Безнекеләргә дә үрнәк алырлык әйберләр шактый булды. Бигрәк тә эшкәртү буенча. Бер егетебез Башкортстанда төзелеш материаллары белән шөгыльләнә. Аның өчен дә яхшы тәҗрибә тәкъдим ителде. Гомумән, без һәр җыеннан ниндидер яңалык күреп кайтабыз. Россиядә мондый чараны татарлардан башка бер генә халык та, республика да оештыра алмый.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

ИСКЕ ЮЛГА – ЯҢА ЯМАУ

Машина йөртүчеләрнең кәефсез чагы. Яз җитүгә, юллардагы чокыр-чакырлар да «уянды» әнә. Социаль челтәрләр юл «капкын»ына эләгеп, тәгәрмәчсез калган машина йөртүчеләрнең моң-зары белән тулды. Тик юлчылар да йоклап ятмый. Көннәр җылынып, кар эри башлауга ук, Татарстанда чокырларны ремонтлау эшенә керештеләр. Юлларга нинди ямау салалар? Илдәге ике бәланең берсе булган начар юллардан котылып буламы? Әлеге сорауларга җавап эзләп, «ВТ» хәбәрчесе юлчылар белән чокырлар ямарга китте.

Автор фотосы

Елак кыш гаепле

«Мин – төбәк дәрәҗәсендәге юлларны карап тору һәм үстерү өчен җавап бирүче оешманың күзләре һәм колаклары», – ди үзе турында уенын-чынын бергә кушып, Альберт Фәйзеханов. Ул – «Главтатдортранс»ның Лаеш һәм Балык Бистәсе районнары буенча кураторы. Бу дүшәмбедә республика күләмендә, шул исәптән төбәк дәрәҗәсендәге юлларда да, чокырларны ремонтлау эшенә керештеләр. Хәер, бу эшнең ел дәвамында туктап торганы юк, ди Альберт Фәйзеханов.

– Юл һәлакәтләренә китермәсен өчен, авария хәлендәге чокырларны кышын да, җәен дә ямыйбыз. Елның һәр фасылына туры килүче технология бар. Язга чыккач, юлдагы чокырлар саны бермә-бер арта. Аларны исәптә тоту өчен юлларга көн саен үзебез чыгабыз. Бүген тигез булган җирдә иртәгә чокыр пәйда булырга мөмкин. Иң беренче чиратта машиналар күп йөргән юллардагы зур «ертык»ларны ямыйбыз, – ди белгеч.

«ВТ» хәбәрчесе Лаеш районының Столбище – Атабай юлында барган тәзекләндерү эшләрен күреп кайтты. Без килгәндә, инде шактый кипшенергә өлгергән юлда өч-дүрт төрле техника, унлап эшче юлларны ямый иде. Бу эшнең дә җае бар: иң элек юлдагы чокырның кырыйларын тигезләп кисәләр һәм эчен вак таштан чистарталар. Көрәкле абзыйлардан соң, зур тузан суырткычка охшаган җиһаз таккан эшче чокырны өрдереп, юлдагы «ертык»ны киптерә. Аннары әзер чокырга яңа асфальт салалар. Аны трактор ярдәмендә тигезлисе генә кала. Атабай юлында эшчеләр юлны кайнар асфальт ярдәмендә ямый. Әлеге технология кипкән юллар өчен яхшы икән. Мондый ямау озаккарак җитә, дип тә ышандырдылар. Чокырларны әнә шулай берсе артыннан берсен ямап баралар. Киңлеге ярты метрдан артмаган, озынлыгы ике метр чамасы бер чокырны ремонтлау өчен ун минут вакыт җитте.

– «Главтатдортранс» карамагында төбәк дәрәҗәсендәге 13600 чакрым юл исәпләнә, – ди оешма директоры урынбасары Зөлфәт Ханмурзин. – Алдагы ел белән чагыштырганда, быел юллардагы чокырлар саны күбрәк. Моңа көйсез һава торышы сәбәпче. Көндезләрен – җылы, ә төнлә салкын булу аркасында юл өслеге тизрәк таушала. Өстәвенә кыш көне бернибә тапкыр бозлы яңгыр да яуды. Бу да юлларга зур зыян салды. Юлларны тәртиптә тоту өчен, хәлдән килгәннең барын да эшлибез. Тик бездән генә тормый шул.

Зөлфәт Ханмурзин сүзләренә караганда, чокыр-чакырларны ремонтлау өчен асфальтны алты заводтан ташыйлар.

– Алар Идел һәм Кама аръягы зоналарында, Чистай, Алексеевск, Кама Тамагы һәм Лаеш районнарында урнашкан. Бирегдән кайнар асфальтны, тиешле технологияләргә туры китереп, якын-тирә районнарга да озаталар. Төзелеш чорында исә республика күләмендә 40ка якын асфальт-бетон заводы эшли, – диде директор урынбасары.

Таш юлны ямау эше күпмегә төшкәнен генә әйтмәде ул.

– Чокырларны ремонтлау өчен аерым чыгымнар каралмаган. Әлеге эш юлларны эксплуатацияләү һәм карап тору кысасында алып барыла. Татарстанда ел саен уртача 250–300 мең квадрат метр мәйдандагы чокырларны ямыйлар, – дип җавап бирде ул.

«Авито» сайтындагы игъланнар арасында, мәсәлән, әлеге төр хезмәтнең бәясе, кулланылган материаллар һәм эшнең катлаулылыгыннан чыгып, бер квадрат метры 300 сумнан алып 1600 сумга кадәр тора. Шуннан үзегез чамалагыз.

– Төбәк дәрәҗәсендәге юлларны тәртиптә тоту өчен республикадагы 8 подрядчы оешма белән килешүләр төзелгән. Алар чокырларны ремонтлау, юлларны чистарту, юл тамгалары урнаштыру кебек эшләрне дә башкара, – дип фикерен җөпләде Зөлфәт Ханмурзин.

Чокырларны ремонтлау эшен 15 майга кадәр төгәлләргә ниятлиләр. Ә аңарчы машина йөртүчеләргә сабыр итәсе генә кала.

Метшиннан бер киңәш

Соңгы бер айда гына да республикада яшәүчеләрдән «Халык контроле» порталына юлларның торышына кагылышлы 400ләп мөрәҗәгать килеп ирешкән. Аңлашыла ки, зар хатларын күбрәк Казан, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама кебек зур шәһәрләрдә яшәүчеләр яза.

Башкала халкын шәһәр мэры Илсур Метшин тынычландырды.

– Чокырларны ремонтлый башлагач, казанлылар: «Суга асфальт җәюдән ни файда?» – дип язарга тотына. Беренчедән, бу – ремонт эшләренә кадәр юлларны яраклы хәлдә тотарга ярдәм итүче вакытлыча чара. Икенчедән, без эш өчен эретеп коелган (литой) асфальт кулланабыз. Ул хәзерге һава шартлары өчен бик яхшы. Шуңа күрә борчылмагыз, – диде шәһәр башлыгы «эшлекле дүшәмбе»дә.

Илсур Метшин әйтүенчә, Казанда иң беренче чиратта төп урамнарны, күперләрне һәм юл киселешләрен ямаячаклар. Шәһәр «бөке»ләргә батмасын өчен, юл эшләрен төнлә башкаралар. Башкарма комитетның Тышкы төзекләндерү комитеты рәисе Игорь Сәләхетдинов сүзләренә караганда, урамда һава торышы +5 градус торганда ремонт өчен эретеп коелган асфальт яхшы. Ә +10 градустан да җылыткач, Казан урамнарына, технологик таләпләр нигезендә, кайнар асфальт түши башлаячаклар.

Чаллыда 300 квадрат метрдан да күбрәк мәйданда чокырларны ямаганнар инде. Шәһәр башкарма комитеты беренче урынбасары Илья Зуев әйтүенчә, иң беренче чиратта тиешле нормадан артып киткән «ертык»ларны ямыйлар. Машина төзүчеләр урамы, Хәсән Туфан проспектында юлларны шомартканнар инде. Юл эшләренә 120 техника җәлеп ителгән.

Әлмәт районы башлыгы Тимур Нагуманов нефть каласында чокырларны ремонтлау эшен мөмкин кадәр тизрәк төгәлләргә вәгъдә итте. Бу хакта ул үзенең телеграмканалында «туры эфир»да сөйләде.

Мөгаен, иң соңгыларыннан берсе булып, чәршәмбе көнне юлларны ямауга Түбән Камада да керештеләр. Ник дисәгез, атна башында гына шәһәр башкарма комитетында: «Юлларны ямарга чыгарга иртәрәк әле», – дип белдергәннәр иде. Бу хәбәр машина йөртүчеләр арасында шактый шаушу тудырды. Рульдәгеләрнең кәефен сизгәннәр, ахры. Чокырларны Бакый Урманче урамыннан ямый башлаганнар. Түбән Камада барлыгы 425 квадрат метр мәйданда эш башкарылачак дип фаразлана.

КЫЙММӘТЛЕ «ТОЗАК»

Ә иртәгә юлчылар килгәнче, бүген чокырга төшеп, тәгәрмәчсез калган машина йөртүчеләргә нишләргә? Үз башына төшкәч, әлеге сорауга җавапны «ВТ» хәбәрчесе дә эзләде. Узган җомгада авылга кайтырга дип чыккач, башкаланың Фрунзе урамында юл «капкын»ына эләгеп, берьюлы ике тәгәрмәч эштән чыкты. Юл чатында безгә кадәр үк унлап машина тора иде инде. Барысы да су астындагы чокырны күрмичә калган. Ике тәгәрмәч тә тишелгәч, беркая китеп тә булмый бит әле, машинада запас тәгәрмәч берәү генә.

– Якынча исәпләп карадым: эвакуатор чакырту – 3 мең сум, ике тәгәрмәчне ремонтлау – 3–4 мең сум, дискларны турайткан өчен тагын 2 мең сум тирәсе өстәп түлисе. Юк кына урында 8–9 мең сумга «эләктем», – ди үзен Илнар дип таныштырган егет.

Гаделлек эзләп, ЮХИДИ хезмәткәрләрен дә чакырткан ул.

– Кайчан киләчәкләре генә билгесез. Көтегез, диделәр. Алар өчен бу җитди юл һәлакәте түгел шул. КАСКО булмагач, чыгымнарны кайтара алуым икеле, дип тә кисәттеләр. Тик мин дә гаепле түгел бит. Юлның сыйфаты өчен җаваплы оешма булырга тиеш, – ди Илнар.

Юл чатындагы ватык машиналары янында басып торган уннан артык машина йөртүченең икесе генә ЮХИДИ хезмәткәрләрен көтәргә калды. Калганнары: «Вакыт кадерлерәк», – дип, ничек тә тәгәрмәчләрне ремонтлау җаен табып, бер-бер артлы кузгала торды. Без дә тишек тәгәрмәчләрне якындагы шиномонтажга калдырып (алары урынына вакытлыча искеләрен биреп тордылар), юлыбызны дәвам иттек. Юл чатында ике сәгатьләп вакыт узды.

Автоюрист Денис Егоров сүзләренә караганда, чокырга эләгеп эштән чыккан тәгәрмәч өчен акчаны суд аша кайтарырга туры киләчәк.

– Чокырларның да үз ГОСТы бар. Аның нигезендә, чокырның озынлыгы – 15, тирәнлеге – 5 сантиметрдан, ә мәйданы 60 квадрат сантиметрдан артмаска тиеш. Әлеге күрсәткечләрнең берсе артып киткән икән, зыян күрүче йөртүче компенсация алырга хокуклы. Моның өчен ЮХИДИ хезмәткәрләрен чакыртырга, чокырны үлчәргә, фото һәм видеога төшерергә кирәк. Тәгәрмәчләрне ремонтлауга киткән чыгымнарның чекларын да саклагыз. Әлеге документлар судка мөрәҗәгать итү өчен кирәк. Бу эшне автоюристларга ышанып тапшырсагыз яхшырак. Дөрес, бу – өстәмә чыгым дигән сүз. Акчаны кайтару өчен шактый тырышырга туры киләчәк. Чөнки машина йөртүче буларак, сез гадәттән тыш хәлне алдан кисәтергә тиеш. Шул ук чокырны, мәсәлән, читләтеп узарга яки аның каршында туктап калырга мөмкин иде бит. Суд еллар буена сузылырга мөмкин.

Юл тозагына эләгүдән беркем дә сакланмаган үзе. Бу көннәрдә генә Чита шәһәре мэры чокырга эләгеп, Lexus автомобилен җимерүен сөйләде әнә. «Шәһәр башлыгы буларак, шәһәр хуҗалыгы комитетын судка бирмим. Тик шәһәр халкы исеменнән фикер йөртүче буларак, 100 мең сумга эләктем», – дигән ул. Бу хәлнең ни белән беткәне билгесез.

Белеп торыгыз!

Агымдагы елның 1 апреленнән 30 апрельгә кадәр Татарстан территориясендәге төбәк әһәмиятендәге юлларда авырлыгы бер күчәренә 6 тоннадан артып киткән йөк машиналары хәрәкәтенә вакытлыча чикләү кертелә, дип хәбәр итә Татарстан Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы. Бу автомобиль юлларын җимерелүдән саклау өчен эшләнә. Вакытлыча чикләүгә бәйле искәрмәләр дә бар.



20 март | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 15.00, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2» 16+
10.00, 23.00 «ПЯТЬ ЛЕТ СПУСТЯ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 22.10 «БӘХЕТ КЫЙПЫЛЧЫКЛАРЫ 2» 12+
12.30 Хоккей. Кубок Гагарина.Матч серии play-off. «Адмирал» – «Ак барс». Прямая трансляция 0+
15.15 Кубок России по баскетболу на колясках. Финал 0+
18.00 «Әдәби хәзинә» 16+
19.00, 00.30 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
00.00 «Каравай». Красота национального костюма 6+
01.00 «Ком сәгате» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00, 00.40 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Идрис Газиев тәкъдим итә». «Сәйдәш театры» 16+
15.25, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30 «Ватандашлар». Нурмөхәммәт Хисамов. Галәмгә ачкыч борынгы китапларда (субтитрлы) 16+
18.20 «Идрис Газиев тәкъдим итә». «Сәйдәш театры» 16+
19.15 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Идрис Газиев тәкъдим итә». «Сәйдәш театры» 16+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Мариэтта Цигаль-Полищук. «Раневская». (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
00.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
01.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
01.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Ирина Пегова, Ярослав Бойко, Наталья Гудкова, Александр Макогон, Максим Радугин, Владислав Резник. «АКУШЕРКА. НОВЫЕ СЕРИИ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Детективный телесериал «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
07.00, 10.00, 12.20, 18.10, 22.30 Новости
07.05, 15.50, 21.45, 00.35 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Тайский бокс. Чемпионат России. Финалы. Трансляция из Магнитогорска 16+
11.30, 23.35 «Магия большого спорта» 12+
12.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/2 финала конференции «Восток». «Адмирал» (Владивосток) – «Ак барс» (Казань). Прямая трансляция
14.50 Смешанные единоборства. UFC. Леон Эдвардс против Камару Усмана. Трансляция из Великобритании 16+
16.45 «География спорта. Благовещенск» 12+
17.15, 03.00 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
18.15 «Громко». Прямой эфир
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/2 финала конференции. Прямая трансляция
22.35 Бокс. Чемпионат мира. Женщины. Трансляция из Индии 0+
00.05 «Здоровый образ. Хоккей» 12+
01.05 Футбол. Чемпионат Германии. «Байер» – «Бавария» 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Локомотив-Кубань» (Краснодар) – УНИКС (Казань) 0+

НТВ

04.55 Сериал «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Денис Никифоров, Дмитрий Лавров, Николай Козак. «ХОЗЯИН» (S) 16+
22.15, 00.00 Боевик «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.45 Прохор Дубравин, Павел Баршак в детективном сериале «ИГРА. РЕВАНШ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.25 «Давай разведёмся!» 16+
09.25 «Тест на отцовство» 16+
11.40 «Понять. Простить» 16+
12.45 «Порча». «Невольник» 16+
13.15 «Знахарка» 16+
13.50 «Верну любимого» 16+
14.25 «Голоса ушедших душ» 16+
15.00 «СЕМЕЙНЫЙ ПОРТРЕТ» 16+
19.00 «СТО ДОРОГ» 16+
23.00 «ПОЗДНИЙ СРОК». 1-я – 4-я серии 16+
02.30 «МАРУСЯ» 16+
04.05 «Порча» 16+
04.30 «Знахарка» 16+
04.55 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.30 «НА РУБЕЖЕ. ОТВЕТНЫЙ УДАР». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня. 16+
09.20, 01.00 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ». «Трудная осень» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «РАЗВЕДЧИЦЫ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Подпольщики». Документальный сериал. «Война – женского рода» 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «СССР. Урановый проект» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «КОНЕЦ ИМПЕРАТОРА ТАЙГИ» 12+
02.05 «С ТОБОЙ И БЕЗ ТЕБЯ...» 12+
03.35 «РАЗВЕДЧИЦЫ». 1-я и 2-я серии 16+

21 март | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2» 16+
10.00, 23.00 «ПЯТЬ ЛЕТ СПУСТЯ» 16+
11.00 «Азбука долголетия» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «БӘХЕТ КЫЙПЫЛЧЫКЛАРЫ 2» 12+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Каравай» 6+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 16+
23.50 «Видеоспорт» 16+
00.15 «Соотечественники». Османие. На пути к вере 16+
00.40 «Каравай». Марийские гусли и волынка 6+
01.05 «Җырлыйк әле!» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Ком сәгате» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Ватандашлар». Нурмөхәммәт Хисамов. Галәмгә ачкыч борынгы китапларда (субтитрлы) 16+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Фоат Галимуллин турында телеочерк (субтитрлы) 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20 «Йөрәктән – йөрәккә». Фоат Галимуллин турында телеочерк (субтитрлы) 16+
19.15 «Музыкаль мәйдан» 16+
21.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Фоат Галимуллин турында телеочерк (субтитрлы) 16+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә»(субтитрлы) 6+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «РАНЕВСКАЯ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
00.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
01.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Фаина Раневская» 16+
01.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Ирина Пегова, Ярослав Бойко, Наталья Гудкова, Александр Макогон, Максим Радугин, Владислав Резник. «АКУШЕРКА. НОВЫЕ СЕРИИ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Детективный телесериал. «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 13.45 «Спортивный век» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 08.35, 12.20, 14.15, 22.30 Новости
07.05, 15.50, 21.45, 00.35 Все на Матч! Прямой эфир
08.40 Лыжные гонки. Альфа-Банк Чемпионат России. Женщины. 10 км. Прямая трансляция из Тюмени
10.20 Лыжные гонки. Альфа-Банк Чемпионат России. Мужчины. 15 км. Прямая трансляция из Тюмени
12.00 Специальный репортаж 12+
12.25 «Есть тема!» Прямой эфир
14.20 «Ты в бане!» 12+
14.50, 03.00 Еврофутбол. Обзор 0+
16.45, 19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/2 финала конференции. Прямая трансляция
22.35 Бокс. Чемпионат мира. Женщины. Трансляция из Индии 0+
23.35 «Магия большого спорта» 12+
00.05 «География спорта. Благовещенск» 12+
01.05 Лыжные гонки. Альфа-Банк Чемпионат России. Женщины. 10 км. Трансляция из Тюмени 0+
02.00 Лыжные гонки. Альфа-Банк Чемпионат России. Мужчины. 15 км. Трансляция из Тюмени 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Матч! Парад 16+
04.25 Классика бокса. Сонни Листон против Кассиуса Клэя. Майк Тайсон против Джеймса Дагласа 16+

НТВ

04.55 Сериал «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ХОЗЯИН» (S) 16+
22.15, 00.00 Боевик «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.45 «ИГРА. РЕВАНШ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.50 «Давай разведёмся!» 16+
08.50 «Тест на отцовство» 16+
11.05 «Понять. Простить» 16+
12.10 «Порча». «Шептунья» 16+
12.40 «Знахарка» 16+
13.15 «Верну любимого» 16+
13.50 «Голоса ушедших душ» 16+
14.20 «ЧУЖИЕ ДЕТИ» 16+
19.00 «ВРЕМЯ ЖЕНИТЬСЯ» 16+
23.15 «ПОЗДНИЙ СРОК». 5-я – 8-я серии 16+
02.50 «МАРУСЯ. ТРУДНЫЕ ВЗРОСЛЫЕ» 16+
04.20 «Порча» 16+
04.45 «Знахарка» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «РАЗВЕДЧИЦЫ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.05 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ». «НАПАДЕНИЕ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «РАЗВЕДЧИЦЫ». 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Подпольщики». Документальный сериал. «В логове зверя» 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «ШОФЕР ПОНЕВОЛЕ» 12+
02.20 «ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА...» 12+
03.35 «РАЗВЕДЧИЦЫ». 5-я и 6-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Районның социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башлыгы **Хәснуллин** Фәрит Мөнәвир улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Рухи-әхлакый хәзинәләрне саклауга һәм үстерүгә, тынычлыкны һәм конфессияара татулыкны ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы һәм Казан шәһәре баш раввины **Горелик** Нахум Ицхак Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының тармак программаларын үстерү һәм эшләү бүлеге башлыгы **Гинсбург** Мария Владимировнага; «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мамадыш муниципаль районындагы «Кайгырту» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе социаль хезмәткәре **Иванова** Русудан Мөхәммәтнәкыйп кызына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Базарлы Матак урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Гарипова** Венера Ибраһим кызына, «Кукмара аграр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Гатин** Азат Хәлил улына, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Мамадыш шәһәренең академик К.Ә. Вәлиев исемендәге 2 номерлы лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Гыйлманов** Салават Мәхмүт улына, «Казан медицина көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Круглова** Зөлфия Фәнүн кызына, Сафаҗәй урта мәктәбе муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе директоры (Пилнә районы, Түбән Новгород өлкәсе) **Мусин** Рамил Хәбиб улына, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «2 номерлы Болгар урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Мөхетдинова** Наталия Геннадьевнага, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Яңа Салман урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы **Яшин** Валерий Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

КЕМ КАЙЧАН УЙНЫЙ?

КХЛДА ГАГАРИН КУБОГЫ ӨЧЕН КӨРӘШ ДӘВАМ ИТӘ

Көнбатыш Конференциясендә ярымфинал уеннары

СКА – «Торпедо»
16, 18 март – Санкт-Петербург, 20, 22 март – Түбән Новгород, 24 март – Санкт-Петербург, 26 март – Түбән Новгород, 28 март – Санкт-Петербург.

ЦСКА – «Локомотив»
17, 19 март – Мәскәү, 21, 23 март – Ярославль, 25 март – Мәскәү, 27 март – Ярославль, 29 март – Мәскәү.

Көнбатыш Конференциясендә ярымфинал уеннары

«Ак барс» – «Адмирал»
16, 18 март – Казан, 20, 22 март – Владивосток, 24 март – Казан, 26 март – Владивосток, 28 март – Казан.

«Авангард» – «Металлург»
17, 19 март – Омск, 21, 23 март – Магнитогорск, 25 март – Омск, 27 март – Магнитогорск, 29 март – Омск.

ҖИҢЕЛЛЕК КИРӘК

Бар мөселман дөньясы рамазан аен каршыларга әзерләнә. Тагын биш көннән уразага керәбез. Бу чорны организмга зыян килмәслек итеп ничек уздырырга? Сәхәр белән ифтардa нәрсә ашарга? Нинди витаминнар эчәргә?



Табиб-диетолог Гөлназ ГЫЙМРАНОВА белән шул хакта сөйләштек.

:: Организмны уразага ничек әзерләргә?
– Иң элек җитәрлек күләмдә чиста су эчүне гадәткә кертергә кирәк. Кешенең 1 килограмм гәүдә авырлыгына 30 мл су туры килергә тиеш. Кичке сәгать уннан да соңга калмыйча йокларга яту хәерле. Йоклаганда мелатонин дип аталган гормон бүленеп чыга. Ул исә гормональ системаны җайга сала. Уразага керер алдыннан печенье, кекс, торт кебек җиңел углеводларны да чикләргә кирәк. Аларны ашаудан туктасагыз, ураза тотканда башыгыз авыртмас.

:: Сүз уңаеннан, ураза тотканда беренче көннәрдә еш кына баш әйләнә, хәлсезлек сизелә, күңел болгана. Бу күренеш нәрсә белән аңлатыла?
– Рамазанга кадәр баллы ризык белән мавыккан булсагыз, шуңа өстәп, әле сәхәрдә дә баллы ризык ашасагыз, канда глюкоза күләме артачак. Ач торганда исә аның күләме кисәк кенә кими. Кандагы шикәрнең шул рәвешле уйнавы баш авыртуга китерә. Организмда җитәрлек күләмдә су булмаса да, баш авыртырга мөмкин. Ач торганда организмда канга токсиннар бүлеп чыгарып, организмны агулый торган бактерияләр, паразитлар үлә. Шуңа күрә рамазан ае алдыннан, хиҗәмә ясатып, кан тамырларын чистартып алсагыз да яхшы булачак.

:: Уразага керер алдыннан организмны тикшерту өчен, анализлар тапшырырга кирәкме?
– Глюкоза һәм гемоглобин күләмен тикшертергә мөмкин. Глюкоза күләме биштән дә түбән булмаска тиеш. Артыграк икән, ураза тотканда кешегә күп дигәндә бер хөрмә (финик) ашарга ярый. Ураза тотучының кандагы ферритин дәрәҗәсе дә 50дән артмаска, үт куыгында таш булмаска тиеш.

:: Сәхәр һәм ифтарда нәрсәләр ашау хәерле?
– Сәхәрдә ат, бозау, сарык ите ашарга була. Әмма аларның күләме 100 граммнан да артмасын. Ник дигәндә, организмның аларны эшкәртеп тә өлгерәсе бар. Моның өчен анда ферментлар җитәрлек күләмдә булырга тиеш. Ит янына яшелчә өстәсәң дә яхшы булачак. Аларны пешереп тә, пешермичә, салат ясап та ашарга мөмкин. Ярмалар да файдалы. Ифтарда да шундый ук ризыклар ашарга киңәш ителә. Бер генә искәрмә бар. Авыз ачканда аксымның җиңел үзләштерелә торган төрләренә, мәсәлән, йомырка, балык, креветка, тавык һәм күркә итенә өстенлек бирергә кирәк. Кыздырылган ризык ашарга уйласагыз, аны эретелгән майда, терлекнең эчке маенда яки иссез авокадо маенда әзерләргә кирәк.

vk.com

УРАЗА ТОТКАНДА КИРӘКЛЕ ВИТАМИННАР

Сәхәр		Ифтар	
витамин	күләме	витамин	күләме
Д	5000 ме	магний	400 мг
С	500 мг		
омега-3	1000 мг		

:: Ураза тотканда кайсы төр ризыкларны ашамау хәерле?
– Бу чорда организмга бернинди файда китерми торган ризыклардан баш тартырга киңәш итәр идем. Монда майонез, торт, конфет, печенье, лимонад, шоколад, каһвә, яшел чәй, эретелгән сыр, чипсы турында сүз бара. Аларны чикләсәгез, үзеннән-үзе җиңеллек сизәрсез.

:: Каһвәгә аерым тукталыйк әле. Ни өчен аны ураза тотканда эчәргә ярамый?
– Бу эчемлек организмнан суны кудыра, кан басымын уйната. Аның составындагы кофеин исә организмны уятып җибәрә, көч-дәрт өсти. Димәк, авыз ачканда каһвә эчкән кеше вакытында йоклый алмаячак. Шуңа күрә ураза тоткан чорда каһвәдән гомумән баш тарту хәерле.

:: Уразада җиләк-җимешләрне кайчан ашау яхшырак?
– Алардан ашаганнан соң ук авыз итәргә мөмкин. Шулай да җиләк-җимештән бигрәк, җиләкләргә өстенлек бирү хәерлерәк. Ураза тотканда тәүлегенә 100–200 грамм җиләк-җимеш ашарга киңәш ителә.

:: Күп итеп су эчкән кеше уразаны җиңелрәк тота, диләр...
– Җитәрлек күләмдә чиста су эчкән кеше, дөрестән дә, уразаны җиңелрәк тота. Ник дигәндә, организм яхшырак чистара, яшәрә, хәлсезләнми. Витаминнар да җиңелрәк үзләштерелә.

Кара дару

Күбебез үз иткән шоколад кәефне генә күтәреп калмый, сәламәтлеккә дә файда китерә, ди белгечләр.

◆Ул баш мие эшчәнлеген яхшырта. Иртүк бер стакан кайнар шоколад эчсәгез, теләсә нинди математик биремнәргә тешегез үтәчәк.
◆Кояштан саклый. Эссе, кояшлы көндә урамга җыенсагыз, шоколадның бер шакмагын авызыгызга алыгыз. Аның составындагы флаванол дигән матдә тән тиресенең саклану катламын активлаштырып, кояшның зарарлы нурларыннан саклый, җыерчыклар, яман шешне кисәтә.
◆Ютәлдән коткара. Кул астында дару булмаса, бер плитка шоколад ашап куегыз. Аның составындагы теобромин хәтта авыр ютәлне дә җиңәргә булыша.
◆Кара шоколадтагы антиоксидантлар яшь булып калу өчен генә түгел, йөрәк-кан тамырлары эшчәнлеген яхшырту өчен дә файдалы. Шоколад нерв системасына уңай йогынты ясый. Организмда эндорфин һәм энкефалин кебек шатлык гормоннары эшләп чыгара.

◆Йөрәккә дә файдалы. Даими шоколад ашаучыларның йөрәк авыруларына дучар булу ихтималы 37 процентка кими.
◆Кәефне күтәрә, баш миендәге серотонин матдәсен арттыра.
◆Ирләрдә инфаркт килеп чыгу куркынычын 17 процентка киметә.
◆Тамак ачуны баса. 10 г шоколад ачлыкны җиңәргә сәләтле.
◆Шоколад яратучылар озаграк яши.
◆Статистика буенча, шоколад яратучы илләрдә Нобель премиясе лауреатлары күбрәк.

Рецепт

БӨЕР ЧИРЕ ҺӘМ ЯМАН ШЕШ БУЛМАСЫН, ДИСӘҢ...

50 г яңа җыелган яшь нарат ылысын 2 стакан суга салып, 20 минут кайнатырга һәм 2 сәгать төнәтергә кирәк. Аннары шуны сөзеп, тәмченә бал кушарга. Ылыс төнәтмәсен көненә 0,5 стакан эчәргә ярый. Ул бөер чирләре булганда, онкология вакытында файдалы. Нарат ылысын көзен һәм кышын җыярга кирәк, бу вакытта ул аскорбин кислотасы, эфир майларына баерак була.

Тукландыргыч битлекләр

Йомырка сарысыннан: чынаякта бер йомырка сарысын туглап, аз-азлап кына 1 бал кашыгы үсемлек мае өстәгез. Чиста биткә шуны ягыгыз да 20 минут тоткач, җылы су белән юып төшерегез.
Балдан: 3–4 чәй кашыгы балга 2 чәй кашыгы лимон согы һәм шул ук күләмдә үлән чәе кушыгыз. Кушылманы болгатып, биткә сөртегез.
Чүпрәдән: яңа савылган сөттә бер кечкенә чүпрә кисәге эретегез дә шул катнашманы биткә сөртегез. Кипкәнче тотыгыз һәм салкынча су белән, иң яхшысы – ромашка төнәтмәсе белән юыгыз. Бит тиресе коры булганда зәйтүн мае өстәргә мөмкин.

ЙОКЫСЫЗЛЫК БОРЧЫСА

Озак вакыт тырышып та, йоклап китә алмасагыз, уң якка ятып, 8гә кадәр санагыз, аннары аркага ятып – 16га һәм сул якка борылып, 32гә кадәр санагыз. Көндез ялкаулык һәм йокы басса, салкын су белән битне чайкарга һәм 1 стакан су эчеп куярга киңәш ителә. Моңа өстәп, бер урында сикерсәгез, көндезге йокыгыз ачылыр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

УЯНЫРГА ВАКЫТ

Бакчаны кышкы «йокы»дан уятырга вакыт җитеп килә. Кар «юрган»ы март кояшы нурлары астында күзгә күренеп эри. Бу чорда агач-куакларга ничегрәк ярдәм итәргә, җирне ничек әзерләргә? Укучыларыбыз сорауларына «Россельхозцентр» оешмасының Татарстандагы филиалы җитәкчесе урынбасары Гүзәл ХӨСӘЕНОВА җавап бирә.

?Алмагачыма әле бер генә «яшь». Ботакларын кисеп, ябалдашын матур рәвешкә кертәсе иде. Бу эшне кайчан һәм ничек дөрес итеп башкарасы?

Клара НИЗАМИЕВА. Чаллы

– Бер яки ике «яшьлек» алмагачның ботакларын (70–100 см биеклектәге) болайрак кисәләр. Өч төп ботагын тәрле якка аерып куялар. Алар бер-берсеннән 10–15 см ераклыкта урнашырга, ә ботакның аерылу почмагы 120 градус чамасы тәшкил итәргә тиеш. Учарланып үссен өчен, бу ботакларны 50 сантиметрга калдырып кыскарталар. Үзәктән чыккан ботакны да бераз кисәләр. Югарыгы ботаклардан чыккан көчле үрентеләрне дә кисеп алырга кирәк. Ә менә үсеп килүче кечкенә ботакларга тимәскә – гадәттә нәкъ менә шулар җимеш бирүчән була. Ботакның киселгән урынын 1 процентлы бакыр купоросы эремәсе (1 л суга 10 г исәбеннән) белән дезинфекцияләргә, шуннан соң аңа «садовый вар» яки кызыл балчык белән сыер тизәге катнашмасы (1:1) сылап куярга онытмагыз.

Алмагач, гомумән, җимеш агачлары ботакларын һәр ел саен кисәргә ярамый. Юкса бу агачның зәгыйфьләнүенә һәм уңышның кимүенә китерәчәк. Һава температурасы +5–6 градустан югарырак күтәрелгәч, җимеш агачы ботакларына корткычларга (мәсәлән, «Биостоп») һәм чирләргә каршы препаратлар («Ризоплан», «Псевдобактерин-2», «Фитоспорин-М») сибү әйбәт. Бу эшне беренче яфраклар күренгәнче башкарып куярга кирәк.

?Роза куакларының өстен ачарга вакыттыр инде, дип уйлыйм. Ләкин төнге суык аларны өшетмәсме икән?

Наилә ҖАМАЛИЕВА. Чирмешән

– Кояшлы көннәрдә роза куакларының һәм җылылык яратучы башка үсемлекләрнең өстен ачкалап алырга мөмкин. Үсемлекләрне чыныктыру, пленка астында парлануын булдырмау өчен кирәк бу. Ләкин төнгә барыбер каплап куярга кирәк әле, чөнки һава температурасы –5тән түбәнрәк төшкән очракта, үсемлеккә зыян киләчәк. Март ахырына таба нәркис, лилия кебек чәчәкләрнең суганчаларын курыкмыйча ачарга мөмкин. Аларга төнге кыраулар янамый.

?Виктория түтәле кардан арчылып килә. Уңышы мулрак булсын өчен, аны язын карау-тәрбияләү серләрен әйтеп үтмәссезме?

Сәвия ГАЛИУЛЛИНА. Балык Бистәсе

– Түтәлдәге кар тулысынча эреп, туфрагы кипшергәч, шиңгән, карт яфракларын җыеп алырга, рәт араларын йомшартырга һәм черемә кертергә иканен беләсездер. Шуннан соң 3 процентлы бордо сыекчасы, «Фитоспорин-М», «Ризоплан» кебек биофунгицид сибү бик әйбәт нәтиҗә бирә.

?Узган елда виноград үсентеләре авырды. Көзен тимер купоросы белән эшкәртергә өлгермичә калдым. Бу эшне яз көне башкарсам, ничегрәк булыр икән?

Виталий СЕМЕНОВ. Балык Бистәсе

– Тимер купоросы әйбәт анысы, тик ул бөреләр ачылуны ике атнага диярлек тоткарлый. Көньяк төбәкләрдә моның зыяны юк, чөнки анда җәй озын. Ә менә безнең төбәктә үсемлекләрнең үсеш чоры болай да кыска. Шуңа күрә бу очракта виноград куакларын бордо катнашмасы яки бакыр купоросы белән эшкәртү әйбәтрәк булачак.

Укучы киңәше

Июньдә кишер ашыйбыз

Шәһәрдә яшәгәч, яшелчә сакларга урын юк. Шуңа күрә кишерне җәй-көз ашау өчен генә үстерәбез. Яшелчәне июньдә үк ала башлау, әлбәттә, аны алданрак утыртуны таләп итә.

Орлыкларны түтәлгә көннәр җылыта башлауга – апрель уртасы яки ахырында чәчәм. Түтәлне көздән казып калдырам. Кар тизрәк эреп бетсен өчен түтәлгә ком сибәм. Чәчәр алдыннан туфракны тырма яки көрәк белән бераз йомшартып җибәрәм һәм буразналар ясыйм.

Кишерне сирәкләп һәм тукландырып азапланмас өчен, инде берничә ел рәттән орлыкларны эчкәннән соң калган чәй яки кофе төбе белән катнаштырып чәчәм. Ни өчен ком белән түгел дисезме? Хәтта иң вагы да орлыктан авыррак булу сәбәпле, кишер авыр тишелә. Ә чәй һәм кофе төбе кишер орлыгы кебек бик җиңел. Катнашманы буразнага сибүнең дә берничә авырлыгы юк. Аны болай ясыйм: 1әр чәй кашыгы иртә өлгерешле кишер орлыгы («Нантская» сортына өстенлек бирәм) белән порошок сыман комплексы минераль ашламага ярты стакан чәй яки кофе төбе өстәп, яхшылап болгатам. Шуннан түтәлгә буразналар ясыйм һәм су сибәм. Аннан соң буразнага, тоз сипкән кебек, шушы катнашманы сибәм. Өстен җиңел туфрак (яшелчә кәлшәсе өчен кибеттән сатып алынган туфрак яки компост) белән каплыйм да кул яки такта белән бераз баскалап тигезлим. Түтәлне пленка белән каплыйм. Шытымнар күренә башлагач, пленканы алып куям. Рәт араларын йомшартып, бераз гына компост яки черемә сибәм дә түтәлгә спанбонд ябам. Аның астында кишер бик яхшы үсә.

Гөлфия НУРИСЛАМОВА. Казан

Тәмле булсын!

Витаминлы язгы аш

РИММА ҖАМАЛИЕВА РЕЦЕПТЫ

Кирәк булачак: 600 г кәбестә, 6 шампиньон (яки 300 г катырылган гөмбә), 1 кишер, 1 баш суган, 1 тырнак сарымсак, 2,5 аш кашыгы томат соусы, яшел тәмләткечләр, рәйхан (базилик), үсемлек мае.

Суган, сарымсак, кишер, гөмбәне (катырылган булса, башта эретергә кирәк) турап, кечерәк кәстрүлгә (яки тирән эчле зуррак табага) салабыз һәм үсемлек маенда 5 минут кыздырабыз. Кәбестәне юка гына итеп турап салабыз һәм барысын бергә тагын 5 минут чамасы пешереп алабыз. Томат соусы, тоз, рәйхан, 4 аш кашыгы су өстәп, сүрән генә утта 20 минут чамасы пешерәбез.

Ашка яшел тәмләткечләр салып, табынга куябыз.

ӘЙБӘТ ФЕН НИНДИ БУЛА?

Көннәр җылытып, яланбаш йөри башлауга, туташ-ханымнар алдында чәчләрне купшырак йөртү мәсьәләсе килеп баса. Бирегә аларга, әлбәттә инде, фен ярдәмгә килә. Арабызда фенын алыштырырга теләүчеләр дә юк түгелдер. Аны сатып алганда, нәрсәләргә игътибар итәргә?

Егәрлеге. 1200–1600 Вт булса, шул җитә. 2100 һәм аннан зуррак егәрлектәгеләре профессионаллар өчен санала. Ул чәчне бик тиз киптерә. Тик шушы вакыт эчендә чәчне күпертәсе яки бөдрәләтәсе дә бар бит әле. Бары тик парикмахер гына чәчне шулай бик тиз матурлый алачак. Шуңа күрә егәрлек артыннан куарга кирәкми. Юка чәч өчен – 1200, куе чәч өчен 1600 Ваттлы фен бик җитә.

Материалы. Корпусы арзанлы пластиктан эшләнгәнен алмаска тырышыгыз. Кибет киштәсендә үк феннан авыр ис килсә, димәк, начар материалдан дигән сүз. Икенчедән, җылыткычының материалына да игътибар итегез. Арзанлы тимердән эшләнгәне чәчләргә зыян сала. Керамикадан ясалганы әйбәтрәк: ул чәчләрне бозмый.

Режимы. Фенның эшләү режимы никадәр күбрәк булса, чәчне төрлечә киптерү һәм күпертү-бөдрәләтү мөмкинлекләре дә зуррак дигән сүз. Гаиләгездә берничә кеше аннан файдалана икән, күбрәк режимлысын сатып алу әйбәтрәк.

Шунысын да онытмагыз: сыйфатлы, димәк, кыйммәтле фенның тышкы сеткасы турмалин матдәсе белән капланган була. Җылынганда, бу катлам бик күп күләмдә ионнар бүлеп чыгара. Ә алар чәчкә уңай йогынты ясый: аны шомартып, «тыңлаучан»га әйләндерә.

Белсәң, зыян итмәс

Эретә беләсеңме?

Туңган итне кыска дулкынлы мичтә эретү дөрес түгел. Итнең тәме һәм файдалы матдәләре югала чөнки. Иң әйбәте – кичтән үк туңдыру камерасыннан суыткыч эченә алып кую һәм шунда эретү.

Ә инде ит бик тиз кирәк булса, целлофан капчыкка салып, краннан аккан салкын су астында тотарга мөмкин. Кайнар суда ярамый: согы чыгып бетәчәк һәм тәмен җуячак.

ТАШЛАМА ИЗГЕ ДОГАҢНАН

Коръәндә: «Аллаһы Тәгалә өч кешенең: ананың – баласына, рәнҗегән кешенең һәм мосафирның догасын һичшиксез кабул итәр», – диелә. Чынлап та, ана догасының көче, кодрәтенә, могҗизалар ясарга сәләтле булуына торган саен инанасың. Аналар баласына нинди теләктә булырга тиеш? Дога кылуның аерым тәртибе, таләпләре бармы?

Сорауларга башкалабыздагы «Әл-Мәрҗани» мәчетеннән Аймөрат хәзрәт ХАҖИЕВ ачыклык кертте.

:: Хәзрәт, «ана догасы» дигән төшенчәгә аңлатма бирик әле.

– Бисмилләһир-рахмәнир-рахим! Барыбызның да ата-анасы, әби-бабайлары бар. Алар безне тәрбияләп үстергәндә үк: «Балам, нинди эш башласаң да, иң элек ата-ана хәер-фатихасын ал», – дия иде. Алар белә: ата-ана фатихасы, аналар догасы хәерле, алар теләгән кабул була. Пәйгамбәребез (с.г.в.) дә шул хакта әйтә. Аналарның балалары өчен кылган догасы бик көчле, һичшиксез, бернинди киртәсез кабуллардан була. Һәр ана өчен, гомумән, ата-ана өчен үз баласы яхшы. Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисендә дә шул хакта әйтелә: баланың нинди буласын, нинди булып үсәчәген ата-анасы билгели. Аналарның баласына кылган догасы – аның гомерлек юлдашы.

:: Әниләр укырга тиешле ниндидер аерым догалар, дога кылуның аерым кагыйдәләре бармы?

– Бала өчен дигән аерым догалар юк. Һәр ана баласына исәнлек, озын гомер, бу дөньяда үз урынын табуны тели. Иң беренче чиратта игелек теләргә кирәк. Әтиәниләр генә түгел, балалар да алар өчен догада булырга тиеш. Яшь буынны үстергәндә дә, ата-анаңа терәк, ярдәмче һәм догачы бул, дип үстерергә кирәк. Газизләре бу дөньядан киткәч тә, алар рухына дога укырлык буын калдырырга кирәк.

:: Әйтик, җәбер-золым кылучының да, начар юлда йөрүчеләрнең дә әниләре бар бит. Баласы нинди булуына карамастан, әнисе аны догадан калдырмаска тиешме?

– Бу дөньяда кешеләр төрле. Һәрбер әти-әни өчен үз баласы яхшы. «Балаң начарлык кылды, ул начар», – дип төртеп күрсәтсәң дә, ана моңа ышанмаячак. «Ул бит яхшы. Мин аны дөрес итеп тәрбияләдем», – диячәк. Әмма, кызганыч, начар юлда йөрүчеләр дә бар. Бу вакытта да аналар баласын догадан калдырмаска тиеш. Яхшы юлга бассын, начар эшләрен ташласын, изге гамәлләр кылсын дип теләргә кирәк. Начарлыкта йөрүче кешеләр өчен бу гамәлләре – Аллаһы Тәгалә сынавы. Аналар моны белә. Шуңа күрә дә андыйларны догадан калдырырга ярамый.

:: Ана догасы кешегә ахирәттә ничек булыша?

– Әйткәнебезчә, ата-ананың балага кылган догасы, хәер-фатихасы – бу дөньяда юлдаш. Бала Аллаһ кушкан юлда булыр,

pinterest.com

үз урынын табар. Ата-анасы баласыннан бу дөньяда риза булса, Аллаһы Тәгалә дә ахирәттә үзенең колыннан риза булыр, иншаллаһ. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Ата-анасына карата начар мөнәсәбәттә булган кеше җәннәтне күрмәс», – дип кисәтә. Аллаһы Тәгалә ахирәттә баланың ата-анасына мөнәсәбәтенә дә карар. Бу дөньяда да ата-ана ризалыгында булуыбыз ахирәттә дә файдага булыр, иншаллаһ!

:: Үз баласына бәддога укучылар да була бит. Андыйлар турында ни диярсез?

– Кешеләргә явызлык теләп, бәддога укучылар бар, билгеле. Бу дөрес гамәл түгел. Динебез моңа каршы. Бәддога ике өлешкә бүленә. Аның яртысы шул кылынган кешегә булса, калган яртысы кылган кешенең үзенә әйләнеп кайта. Шуңа күрә бәддога кылу динебездә рөхсәт ителми. Бәддога укылып та, укылган кешесен тапмаса, тулысы белән аны кылган кешегә кайтачак әле. Начарлыгың үзеңә кайта, кыскасы. Әниләр балаларын тугыз ай йөрәк астында йөртә, тугач та, тәрбияли, ризыгын, гыйлемен бирә. Чын ана баласына бәддога укый алмый. Һәр ана өчен үз баласы – газиз, яхшы, кадерле һәм ул аңа бары яхшылык кына тели.

Гыйбрәт ал!

Яман сүз җәннәткә кертми


pinterest.com

Беркакыт Гайсә пәйгамбәр үз иярченнәре белән урамнан узып барганда, каршыга очраган бер кеше аны бик начар сүзләр әйтеп сүгә башлый. Пәйгамбәр исә аңа яхшы, матур сүзләр белән җавап бирә. Соңыннан моңа шаһит булган бер юлдашы, аптырап, бу хакта сорагач, Гайсә галәйһиссәләм болай җавап бирә: «Һәркем үз күңелендә булганы белән бүлешә».

Дөрестән дә, тәртипле, тәрбияле кешенең күңеле саф, чиста булу сәбәпле, аннан беркайчан да, бернинди дә пычрак чыкмый. Әмма шунысы аяныч: кайчакта күңеле нәҗес белән тулган кеше шул пычрагын пакь күңелле кеше янында чыгарып, аның күңел «бүлмә»сен нәҗесли. Бу, асылда, берәүнең шакшы тулы чиләген түр бүлмә уртасына бушаткан шикелле була...

Яман телле кешене ишетүдән яңашәдәгеләр җимергеч көчкә ия булган начар сүзләрне үзләре дә теләмәстән күңелләренә сеңдерә, ә бу аларның (бигрәк тә балаларның) хисси җанына һәм тәненә шактый зур зыян сала.

Россиядә кибетләрдә сатылган лицензияле уенчыкларның 40 проценттан артыгы сыйфатсыз. Балалар товарлары индустриясе ассоциациясе башлыгы Антонина Цицулина шулай ди. Балалар арасында аеруча популяр булган «Маша һәм аю», «Өч песи», «Смешарики» кебек мультфильм геройларын гәүдәләндергән уенчыкларның күбесе идән астындагы цехларда тегелә дигән сүз бу.

Якын арада бу мәсьәләдә боз кузгалырга охшап тора. Россиядә балалар өчен чыгарылган барлык уенчык, мультфильм һәм ризыкларны тикшерергә җыеналар. Дәүләт Думасы депутаты Виталий Милонов бу көннәрдә шундый тәкъдим белән чыккан. Аның нияте хуплау таба калса, кибетләрдә сатылган барлык балалар уенчыклары, ризыклар, алар өчен чыгарылган мультфильмнар җиде кат иләк аша узачак.

Татарстан Иҗтимагый палатасы әгъзасы, «Татарстанның күпбалалы гаиләләре» төбәкара иҗтимагый оешмасы рәисе Артем Кузнецов бу эшнең нәтиҗәле булачагына шикләнеп карый.

– Әлеге тикшерү уенчыкларны маркировкалаганда куелган таләпләрне күбәйтеп, аларның бәясен арттыруга гына китерәчәк. Сыйфаты шул ук калачак. Аннары базардагы барлык уенчыкларны тикшереп, аларның сыйфат дәрәҗәсен яхшырту, миңа калса, гомумән, мөмкин эш түгел. Бәясенә күрә сыйфаты. Акчасы булган кеше уенчыкның да яхшырагын алырга тырыша. Мөмкинлеге юк икән, ул аның сыйфатына карап тормый инде, акчасы кайсына җитә, шунысын ала, – ди ул.

Күп бала әтисе үзе уенчык сайлаганда иң элек аның тышкы кыяфәтенә игътибар итә икән. «Үземнең күңелемә ятмаган уенчык балама да файда китерәдер дип уйламыйм. Пластмасс уенчыклардан начар ис килсә, алмыйм. Аның зыянлы икәне көн кебек ачык», – ди Кузнецов.

Татарстанның атказанган артисты Ландыш Нигъмәтҗанова исә, уенчык сатып алганда, иң элек аның бәясенә игътибар итә.

– Кирәксә-кирәкмәсә уенчык ала торган гадәтебез юк. Балалар күп булгач, берсенең уенчыгы икенчесенә кала. Туган көннәргә, бәйрәмнәргә дә күп бүләк итәләр. Үзебезгә алырга туры килсә, иң элек аның бәясенә игътибар итәм. Уенчык кыйбатрак булган саен, ул сыйфатлырак була, билгеле, – ди җырчы.

Илкүләм халык фикерен өйрәнү үзәге (ВЦИОМ) белгечләре уздырган тикшеренү нәтиҗәләренә ышансаң, ата-аналарның күбесе (60 проценты), уенчык сайлаганда, иң беренче чиратта, баласының нәрсә яратуына игътибар итә икән. Респондентларның 57 процентына – уенчыкның кызыкландыргыч булуы, 32 процентына бәясе мөһим. Бу уңайдан газетабызның социаль челтәрдәге сәхифәсендә дә сораштыру уздырдык. Анда да фикерләр аерыла.

Киеме дә сыйфатсыз

«Россия сыйфат системасы» оешмасы белгечләре соңгы арада аеруча популярлашып киткән Чебурашка уенчыгын да тикшерергә булган. Билгеле булганча, ел башында ил кинотеатрларында шул исемдәге фильм күрсәтелде. Миллионлаган карау җыйган әлеге кино өлкәннәрнең генә түгел, балаларның да күңеленә хуш килде. Шуңа бәйле рәвештә Чебурашка уенчыгына да ихтыяҗ бермә-бер артты. Кибеткә керә-керешкә дә иң беренче шул уенчык күзгә ташлана. Бәяләре төрле. Араларында 500–600 сумлыклары да, 2–3 меңлекләре дә бар. Маркетплейсларның берсендә Чебурашка уенчыгын 57 мең сумга (!) ук саталар.

Әмма соңгы арада ата-аналарны, әлеге уенчыкның бәясеннән бигрәк, сыйфаты борчый башлаган. Сыйфат оешмасына мөрәҗәгать иткән ата-аналарның күбесе Чебурашка уенчыкларының сыйфатсыз материалдан тегелүеннән, аларның авыр ис килү, тышкы кыяфәте коточкыч булудан зарланган. «Бүген әлеге төр уенчыкларның күбесе, дөрестән дә, тиешле таләпләргә җавап бирми. Шактый кыйммәт торган Чебурашкаларның да күбесе сыйфатсыз. Шуңа күрә әлеге төр уенчыклар арасында планнан тыш тикшерү оештырылачак», – диелә ведомство хәбәрендә.

Хәтерләсәгез, әле күптән түгел генә сыйфат оешмасы балалар арасында популяр булган Хагги Вагги уенчыкларын да тикшергән иде. Тикшерү барышында белгечләр бу уенчыкларның 60 процентында агулы матдәләр, аерым алганда фенол барлыгын ачыкласаннар. Психологлар Хагги Вагги уенчыкларының бала психикасына да тискәре йогынты ясавын белдерә.

Белгечләр фикеренчә, балалар кибетендә сатылган һәр өч киемнең берсе шулай ук сыйфатсыз. «Россия сыйфат системасы» оешмасы күптән түгел генә бала тудыру йортларында сабыйларга бирелә торган бүләкләрне дә тикшергән. Оешма җитәкчесе урынбасары Елена Саратцева сүзләренә караганда, тикшерү барышында 30 төрдәге 880 балалар уенчыгы иләк аша уздырылган.

– Моннан өч ел элек Россиянең кайбер төбәкләрендәге балалар тудыру йортларында «Яңа туган балага бүләк» акциясе игълан ителде. Аның кысасында яңа туган нарасыйларга бүләккә комбинезон, эчке кием, подгузник кебек кирәк-яраклардан торган җыелма тапшырыла. Тикшерү барышында без шундый һәр өч кирәк-яракның берсе сыйфаты буенча келәймәдә күрсәтелгән мәгълүматка туры килми, дип нәтиҗә ясадык. Табигый материалдан дип язылган балалар киеменең күбесе ясалма материалдан тегелгән булып чыкты, – ди белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Балага уенчык сайлаганда нәрсәгә игътибар итәсез?



- бәясенә.......... 27%
- сыйфатына.......... 43%
- популярлыгына.......... 10%
- кайда җитештерелгәнлегенә.......... 20%

(«ВКонтакте»дагы төркемдәге сораштыруда 77 кеше катнашты)

«Сыйфатсыз уенчык йөрәккә бәрә»

Сыйфатсыз уенчык баланың психикасына да йогынты ясый алامы? Шул сорау белән педагог-психолог, балалар психологы Регина ФӘХРИСЛАМОВАга мөрәҗәгать иттек.

– Авыр ис килгән, артык каты тавышлы, чамадан тыш ачык төстәге сыйфатсыз уенчык баланың психикасына да зыян сала, билгеле. Ул аның ис сизү, ишетү, күрү сәләтенә бигрәк тә зарар китерә. Бала сыйфатсыз уенчык белән уйнаган саен, шушы әгъзалары эштән чыга, димәк. Моннан тыш сыйфатсыз уенчык баланың үз тойгыларына сизгерлеген дә киметә. Ник дигәндә, тышкы кыяфәте ягыннан балага бик нык ошаган уенчык бер үк вакытта тавышы, төсе, исе белән аны ярсыта да булып чыга. Бу киләчәктә баланың физик һәм психик саулыгында хилафлыклар китереп чыгара ала. Аерым алганда, анда психик тайпылышлар, йөрәккан тамырлары авырулары, аллергия башланырга мөмкин.

– Белгеч буларак, хәзерге уенчык базарын ничек бәялисез? Заманча уенчыкларның кайсы бала өчен аеруча куркыныч?

– Баланың психикасына, уенчыклардан бигрәк, аларга бәйле мультфильм һәм уеннар йогынты ясый. Балалар үзләре яраткан персонажлар кебек булырга, аларның гамәлләрен, гадәтләрен кабатларга ярата. Уенчык болар турында гел искә төшереп тора. Шуңа күрә шушы уенчык аша персонажның үз-үзен тотышы тора-бара бу баланың гадәтенә үк әверелергә мөмкин. Бала кечерәк булган саен, ул мультфильм геройларының гадәтләрен дә тизрәк сеңдерә. Шуңа күрә мондый уенчыклар алар өчен күбрәк куркыныч тудыра. Бүген кибетләрдә тулып яткан Хай, Хагги Вагги кебек уенчыклар бала психикасы өчен аеруча куркыныч. Бала гел шундый рухтагы агрессив уенчыклар сорап тилмертә икән, аның эчке халәтенә игътибарлырак булырга кирәк.

– Теге яки бу уенчык аркасында, баланың психикасына зыян килгәнне ничек чамаларга?

– Әгәр бала агрессивка әйләнсә, тиз кызып китсә, гел елап, нәрсәдәндер курка башласа, ата-анага бик игътибарлы булырга кирәк. Баланың нәрсә сөйләвен, уенчыклар белән ничек уйнавын да күзәтегез. Гадәттә, балалар эчке дөньясындагы бөтен уй-фикер, проблемаларны уенда чагылдыра. Хәлләр мөшкелләнә барганны сизсәгез, кичекмәстән белгечкә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

– Чамадан тыш күп уенчык баланы боза, дигән фикер белән килешәсезме?

– Монда иң элек баланың яшенә игътибар итәргә кирәк. Бу яшьтә бала тәүз, этеп йөрү кебек гади генә күнекмәләр ярдәмендә дөньяны танып белергә өйрәнә. Шуңа күрә бер тапкыр уйнаганда аңа ун төрле уенчык җитеп тора. Бала үсә барган саен, аның үсеше өчен кирәкле уенчыклар саны да арта бара. Әмма бу капчык-капчык уенчык җыярга кирәк дигән сүз түгел. Бер төр уенчыкларны җыеп куеп, бераздан шуларны ук чыгарсаң, балага гел яңалык бар кебек тоелачак.

Балага уенчык сайлаганда, нәрсәләргә игътибар итәргә?

✷Базар, юл асты кичүе, шикле киоск кебек җирләрдән уенчык алырга киңәш ителми. Бәясе арзан булса да, зыяны күбрәк була. Шуңа күрә уенчыкны үз абруен саклый торган эре кибетләрдән алу хәерле.

✷Сыйфатлы уенчыкның кабында CE тамгасы (Европа стандартлары буенча эшләнгән дигәнне аңлата. – **Д.Г.**) булырга тиеш.

✷Уенчыктан авыр ис килсә, ул агулы пластик һәм резин кебек арзанлы, сыйфатсыз материаллардан эшләнгән дигән сүз.

✷Уенчыкны ышкып карагыз. Буявы купса, кулга төсе йокса, аны сатып алмау хәерле.

✷Артык каты тавышлы уенчыкларны да читләп үтегез. ГОСТ таләпләре буенча өч яшькә кадәрге балалар өчен сатылган уенчыкларның тавышы – 60 децибелдан, өч яшьтән зурракларныкы 65 децибелдан да катырак булмаска тиеш.

✷Сыйфатлы уенчыкның составында поливинилхлорид (ПВХ) дигән матдә булмый. Бу матдә булмаган уенчыкның кабында «PVC free», «Составында BPA юк», «Chlorine Free Label» дигән тамгалар була.

✷Сыйфатлы уенчыкның җөйләре яхшылап эшкәртелгән булырга, буявы купмаска, йоны коелмаска тиеш.

100 ЯШЬЛЕК НУРАНИЯ ГАЗИЕВА:

«КЫЗЫМНЫ БИЕТӘМ ӘЛЕ»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Мин Төмән өлкәсенең Түбән Тәүде районындагы Киндер авылында туганмын. Әтием Апасныкы, әнием Яшел Үзәнneke, бәхет эзләп, читкә киткәннәр. Алар икесе дә бик укымышлы кешеләр була. Әти бай малайларын укырга өйрәтә. Әни исә хатын-кызларга белем бирә. Ул елларда укый-яза белмәүчеләр күп иде. Ул чакта авыл кешеләре үзләренә килгән хатны да безгә алып килеп укыттылар. Әни алар өчен хат язып сала иде. Кыскасы, бөтен авылның сере бездә булды, – ди Нурания әби. – Әниебез бик гыйлемле иде. Авыл балалары: «Зәйнәп апа, әкият укы әле», – дип килерләр иде. Ул шул заманда иҗат иткән кешеләрнең китапларын укып барган икән. Үзем мәктәптә эшли башлагач, әнинең Мәҗит Гафуриның китапларын укып, безгә сөйләгәнен аңладым.

Кызганыч, әтиләре озын гомерле булмый аларның. Әмма ул өч кызын да укытырга өлгерә. Нурания, 10 нчы сыйныфны бетергәч, читтән торып укырга керә дә мәктәптә эшли башлый. 1940 нчы еллар була бу. Аннары инде сугыш башлана. Башкалар кебек авырлыкларны да күп күрергә туры килә аңа. Черек бәрәңге дә әләгә, алабута, сәрдә, балтырган да ашыйлар. Озын гомерле булуның серен дә үлән ашауда, ач торуда күрә ул.

– Ул чакларны искә төшерсәң дә, күңелгә читен. Аяклар җылыга тиенә алмады. Әмма шулай да бирешмәдек. Нинди авыр елларда да балаларны укыттык. Сабыйларның хәлләре дә булмый иде, әмма алар уку калдырмады, – дип искә ала Нурания әби.

Алар ире Хәмит белән сугыш беткәч гаилә коралар. Ул да укытучы була. Бар гомерләрен балаларга белем бирүгә багышлыйлар. Үзләренең дә өч баласы, Төмәндә югары белем алып, зур дәрәҗәләргә ирешеп яшиләр.

– Олы улым Наил Казанда яши. Рос) сиянең атказанган экологы, хезмәт ветераны. Уртанчы кызым Мәдинә гомере буе мәктәптә эшләде. Аңа хәзер 73 яшь инде. Кияү белән мине тәрбиялиләр. Кече улым Мансур Мәскәүдә яши. Ул – профессор, икътисад фәннәре докторы. Шул балаларымның уңышларына сөенеп, алар игелегендә яшәп яту инде. Кызым белән кияүгә рәхмәтлемен. Әле кызымны биетеп кенә торам. Сабый бала тәрбияләгәндәй карыйлар. Беркөнне киленем дә шалтыратып ята: «Син бик бәхетле, әнкәй. Үз аягыңда йөрисең, үз акылыңда», – ди. Бәхетле шул, балам. Һәр әнигә шуны телим, – ди йөзьяшәр.

Күптән түгел Нурания Газиева янына Татарстан Рәисе дә килде. Әбекәй шуңа бик сөенгән инде. Сөйләп туя алмый.

– Рөстәм Миңнеханов белән бергә сөйләшеп чәй эчеп утыр әле син! Кемгә эләккән бәхет әле бу? Йөз яшькә тикмәгә җитмәгәнмен икән, дим. Рәхәтләнеп сөйләштек. Рөстәм улым күкрәгемә медаль такты. Татарстан Рәисе белән янәшә утыру – минем өчен зур вакыйга инде! Карчык кешенең хәлен белсен әле, – ди Нурания әби. – Бигрәк үзебезнең кеше инде ул. Һәр сүземне тыңлап утырды. Берәр гозерең юкмы, дип сорады. Үтенечемне әйттем мин аңа. Кешегә сөйләмим, үзе белә ул. Исән-сау гына булсын. Мондый җитәкче барда матур яшибез әле.

Нурания әби бар яктан хөрмәтле булып яши. Үзе белән бер елларда укыткан хезмәттәшләре дә, укучылары да онытмый аны. Дуслары күп, ди үзе. «Йөз яшьлекләрмени?» – дигәнемә, кеткелдәп көлеп җибәрә. «Бераз яшьрәкләр, үз тиңнәрем исән түгел бит инде», – дип тә өстәп куя.

– Беркөнне телевизорны ачып җибәрсәм, бер укучым сөйләп басып тора. Алып баручы татарчасын мактагач, укытучым Нурания Газиевага рәхмәт, ди. Диванда ятып торган җиремнән сикереп үк тордым. Әле мине онытмыйлар икән. Димәк, хезмәтем юкка китмәгән, – ди Нурания әби.

Татар теле дигәннән, әбекәйне үз телен онытучылар да борчый.

– Татар телен сакларга кирәк! Чит тел белән белемле булып булмый. Үз ана теләң кирәк. Хәзерге ата-аналарның гаиләдә татарча сөйләшмәве, телне бозуы бик борчый мине. Бар да үзебездән тора бит. Телне бетерәләр, дип кемнедер сүккәнче, үзең берәр нәрсә эшлә, – ди әбекәй. – Аннары, ник мәктәпкә балага телефон тоттырып җибәрәләр икән? Бер яктан, аңлыйм да инде мин. Әти-әни сабые белән элемтәдә булыр өчен сатып аладыр аны. Әмма дәрестә телефонда утыру эш түгел. Үземнең дус кызлар белән бу хакта да сөйләшәм бит мин. Кулларында телефон, дәрес тыңламыйлар, бернишләтә алмыйбыз, диләр. Әмма бу юньлегә илтмәячәк. Балалар надан кала бит. Инде болай да башларын эшләтмиләр, китап укымыйлар.

Әбекәй сөйли, мин исем-акылым китеп тыңлап утырам. Бер генә дә ялгышмый бит. Кызы Мәдинә ападан кайбер сүзләрне, дөресме, дип кире сорыйм. Әби бер дә ялгышмаган. Менә сиңа мә! Үз гомеремдә өлкәннәр белән күп аралашсам да, Нурания әби кебек кешене беренче очраттым. Озын гомер сере нидә соң? Әбекәйнең ничек ашавын, яшәвен сорашам.

– Әллә нинди күнегүләр ясап ятканым юк. Соңгы вакытта бераз аяк сиздерә башлады. Сызлап куя. Сызлар да. 100 ел йөреп кара син! Колагым начаррак ишетә. Башка зарым юк, – ди. – Кайчакта төнлә яхшы йоклыйм, кайбер көнне уйланып ятам. Соңгы арада әниемне сагына башладым әле. Ачлы-туклы яшәдек. Әнине кадерле алмаганыма үкенәм. Әнә мине ничек итеп хөрмәтлиләр бит! Шөкер, тамагыма да ашыйм. Өстәлдән камыр ризыгы, майлы ит өзелми. Мин күп итеп ашамыйм шул. Чамасын белеп, үземә җитәрлек кенә кабып куям.

Мәдинә апа исә әнисен кадерләргә тырыша. Нәрсә ашыйсы килсә, шуны алып торалар. Кирәк чакта табибка барып күренәләр. «Әлегә, шөкер, әнинең анализлары минекеннән яхшы», – ди ул.

– Бик рәхәттә яшим бит, балам. Нинди мул тормышка туры килдем. Көн туган саен Путинга рәхмәт укыйм. Пенсияне түләп бара. 39 мең сум алам. Эшләгән кешегә дә эләкми бит әле ул. Ничек инде рәхмәтле булмыйсың, – ди Нурания Газиева. – Телефоным булса да, интернетларны белмим. Менә анысын өйрәнә алмадым. Әмма кеше белән сөйләшергә яратам инде. Берәрсе шалтыратса, бәйрәм була. Миңа шалтырат син, кызым, рәхәтләнеп сөйләшербез, яме!

ЯШӘП КАЛЫЙК!

Әлеге сүзләр Биектау районының Шәпше авылында яшәүче Фәрит Гыйниятуллинның тормыш девизына әйләнгән. Сынап та карый аны язмыш! Әмма шулай да авырлыкларны җиңәргә көч таба ул.

Хатыны белән аерылышкан чакта игезәк кызларына 9 гына яшь була. Аларны әтиләрендә калдыралар. Инде яңа тормыш корып, матур гына яшәгәндә, Фәрит ике аяксыз кала. Ярты сүздән аңлаучы Риммасы ярдәмендә үзен кулга алып, тормышның якасына ябышып яши башлый.

– Бар авырлык берьюлы килде миңа. Гаиләмнең дә сыналган чагы иде. Хатыным белән аерылышырга туры килде. Суд балаларны миңа бирде, – дип сөйли Фәрит.

Шушы ике баласы хакына үзендә яшәү көче таба ул. Ничек итсә итә, аякка баса. Озакламый тормыш сукмагында Римма очрый. Ул да ире белән аерылышкан, ялгызы бер кыз үстерә. Гаилә берләшеп, тату гына яшәп китә.

– Эльвира кызымны узган ел кияүгә бирдек. Эльмира да чыгасы иде, тик кияү буласы егетне махсус хәрби операциягә алып киттеләр. Хәлен белеп торабыз инде, – ди Фәрит.

Өченче кызлары апрель аенда кияүгә чыгарга җыена. Фәрит исә шушы кызының туена барыр өчен йөрергә өйрәнә.

– 43 яшемдә аякларымны кистеләр. Йөгереп йөргән кеше идем. Дөрес, күп эшләдем. Салкын да тигәндер инде, аякларга ял да җитмәгәндер. Көнаралаш тәүлекле эшкә чыга идем. Табиблар, аякларыңда кан йөрми, диделәр. Алдан ук күренергә кирәк булган икән. Тик мин үзем суздым. Әле аякларыгызны кисәргә кирәк дигәч тә, карыштым. Ясаласы операциядән баш тарттым. Ярый әле хирург бик яхшы кеше булып чыкты. Ул хатыныма барысын да аңлаткан. Бары тик аякларны кисеп кенә, минем гомерне саклап була дигән, – дип сөйли Фәрит. – Яшермим: беренче вакытта бик авыр булды. 1 метр да 85 сантиметрлы ир-ат ярты гәүдәлегә калсын әле. Иң кыены шул булды. Аякларымда басып йөргән чакларымны сагындым. Еладым да. Беләсезме, кешеләрнең мине кызгануыннан йөрәккә кыен була иде. Мин инде йөри алмаячагыма күнеккән идем. Тик менә башкаларның сүзләре йөрәкне өтәләде.

Фәрит операциядән соң 2 ай өйдә генә була. Коляскада йөри. Бервакыт өйдә үзе генә калгач, коляскадан төшеп, урмәләп карый. Әкренләп өйне урап чыга. Була икән бит. Шуннан урамга чыгып китә. Үзен сынап карар өчен, куллары белән генә тотынып, баскычтан өй түбәсенә кадәр күтәрелә. Аннары ишегалдында яткан утыннарга күзе төшә. Хатыны кызының тау шуа торган чанасын бирә. Шуның белән Фәрит ишегалдындагы утыннарны ташый.

– Машинаны сатып, икебез утырып йөри алырлык квадроцикл алдык. Менә шуннан мин чынлап яши башладым. Күзгә тормыш күренә башлады. Абзарга чыгам, нидер җитми сыман. Тавык-чебешләр алдык. Аннары инде үзебездә чеби-үрдәк чыгарырга уйладык. Безнең 10лап күркәбез дә бар иде. Шуларның йомыркаларыннан бибиләр чыгарып карадык. Аннары инде тавык, үрдәк йомыркаларын алып кайтып куштык. Бытбылдыклар үрчеттек. Аларның йомыркаларын кая куярга белми башладык. Башта бушлай тараттык. Хәзер инде җитми дә. Әнә шулай әкренләп эшләр җайланды, – ди Фәрит. – Ике ай элек миңа дигән протезлар әзер булды. Шуларны киеп йөреп тә карадым. Кызымны кияүгә бирәсем бар бит.

Фәриткә әнә шул кызларны үстерәсе, кеше итәсе, кияүгә бирәсе бар дигән сүзләр яшәргә көч биргән дә инде. Бала җанлы булган ул! Өч кызын да бертөрле яратып, кадерләп үстергән.

– Уләргә беркайчан да соң түгел дип яшим. Аяксыз да яшәп була икән. Елап утырсаң, берни барып чыкмый. Кеше үз язмышын үзе яза, – ди Фәрит. – Гомер дигәнең бигрәк тиз уза. Шуңа күрә һәр көннең, мизгелнең кадерен белеп яшәргә кирәк!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЛИЛИЯ ХӘМИТОВА:
«БУ ХӘЛЛӘР ӨНДӘМЕ ДИП, ӘЛЕ ДӘ ШАККАТАМ»

Халык мәхәббәтен яулаган, әмма радио-телевидениедән сирәк яңгыраган җырчы Лилия ХӘМИТОВА бу көннәрдә янә телдән төшми. Башта җырын яңача башкарып, игътибарны үзенә җәлеп итсә, хәзер шәхси тормышы кызыксыну уятты. Ул бүген нинди уй-ниятләр белән яши? Эстрада, репертуар, танылу юллары турында нинди фикердә? Без әнә шул хакта сөйләштек.

:: Лилия, мөмкинлек булса, менә хәзер тормышыгызда нәрсәне үзгәртер идегез?

– Язмышың син уйламаганда-көтмәгәндә дә үзгәреп куярга мөмкин икән. Әйтик, менә Винарис Ильегет үзенең юбилеенда миңа тәкъдим ясады. Көтелмәгән хәл булды. Аның турында уйлаганым да юк иде хәтта. Әни дә авырый, бала да укый – нинди кияүгә чыгу ди ул?! Ә ул тотты да күпме халык алдында игълан итте. Андый эш турында әйтеп куялар инде, дидем әле үзенә. Мин бит Винарисны энекәшем кебек кабул итәм. Дуслыгыбызга 20 елдан артык, бергә чыгышлар да ясадык, инде уртак дусларыбыз да байтак. Әмма шундый тәкъдим ясар дип башыма да китермәдем. Башта ышанмадым да әле. «Шаяртумы бу, миңа нишләргә?» – дип тә сорадым, колагына гына пышылдап. «Юк, бу шаярту түгел», – ди. Хәзер уйлыйм: миндә бит мәхәббәт хисе калган. Ходай әнә шул хисне бүлешергә мөмкинлек биргәндер, күрәсең.

:: Ирләр эшен дә эшлим, дигәнегез бар, ә менә ир хатыны булып кадердә яшәү турында уйлый идегезме?

– Бу хыял һәрбер хатын-кыз күңелендә була торгандыр. Әмма андый кеше синең янәшәңдә генә дип, бер генә хатын-кыз да уйламыйдыр. Минем белән дә шул ук хәл булды. Әнигә әйткән идем, нишләвең бу, дип бөтенләй аптырап калды. «Синең улың да бар бит», – ди. Улым Әмиргә хәлне аңлатып биргән идем, «Әни, ә син нәрсә югалтасың соң?» – диде. Чыннан та нәрсәне югалтам, нәрсәдән куркам соң мин? Әни минем гел янында булуыма ияләнгән инде ул. Хәер, ни генә булса да, без аны ташламаячакбыз. Әмиргә исә – 18 яшь, җиткән егет инде ул. Миңа ирләрчә киңәш биргәч, дөрес тәрбия биргән икән дип уйладым. Алай да, тәкъдим ясадылар да, чыгып киттем дигән сүз түгел. Миңа әлегә кәләш роле бик ошый. Яшерен-батырын түгел, тормышымда менә шушылай матур итеп тәкъдим ясаулары да беренче тапкыр. Моңарчы никах белән яшәп карадым, аннан Әмир туды. Улымны үстерергә, аякка бастырырга әни булышты. Винарисның исә элек-электән әчкерсезлеге ошый иде. Аның белән юлга чыгып китсәң дә, күңелең тыныч. Димәк, урамда калмыйсың, концертның да әйбәт узачак, артистларга да тәрбия булачак. Бу яктан чын ир ул. Ләкин, мин аңа беркайчан да иргә караган кебек карамадым. Гәрчә бергә калган моментлар булса да. Ул миңа туганым кебек якын. Аның миңа мөнәсәбәте башкаларга караганда аерылып тора иде. Кемгәдер тавыш күтәрә алса да, миңа беркайчан да тавыш күтәрмәде. Хөрмәт итә дип уйлый идем. «Мин сине яратам», – дип әйткәне булды. Дежур фраза дип кабул итә идем. Алай гына булмаган икән.

:: Сезнең тавыш та, репертуар да беркемне дә кабатламый, мәгънәле, халыкчан. Алай булса да, сәхнәдән югалып тордыгыз. Сәбәбе нәрсәдә?

– Гастроль тормышыннан өзелгәнем булмаса да, солянка концертларда даими катнашсам да, экраннардан югалырга туры килде шул. Экраннарда күренмәгәч, халык югалды дип уйлый. Ә инде радио-телевидениегә чыгар өчен өстәмә көч һәм чыгымнар кирәк. Соңгы елларда бөтен көчем, игътибарым әнигә булды. Биш ел элек сөягендә яман шеш авыруы таптылар, без әнә шул казага каршы көрәштек. Бу төр авыруның үз куркынычы бар. Аңа егылырга, бәрелергә ярамый. Кыскасы, сөяк сынудан сакланырга кирәк. Шуңа күрә гел янында булырга тырышам. Мин инде шәхси тормыш турында да, иҗат турында да уйланмадым, ник дигәндә, баланың ата-анасы каршындагы бурычы ул һәрвакыт беренче урында. Алай да бөтенләй үк югалмадым инде мин. «Мәйдан» каналында җырларым бар. Кызганыч, элеккеге җырлар телевидение фондында сакланмаган. Менә андый җырларны яңадан яздырабыз. Радиодан да, буран чыкса, «Буран дулый» җырын куйганнарын беләм (*көлә*).

:: «Буран дулый» җырын ни өчен яшь егет белән башкардыгыз? Бу сорауны бирүчеләр күп булгандыр.

– Мин аны дуэт белән җырлармын дип планлаштырмаган идем. Руслан Трапезников белән эшләү үзенә күрә бер кызыклы тәҗрибә булды. Образ үзгәртүләр, заманча клип минем өчен шаккаткыч булды. Кешене стилистлар танымаслык итеп үзгәртә ала икән. Яшьләрнең тормышка карашы икенче һәм алардан нәрсәгәдер өйрәнеп тә була. Ни өчен Руслан дигәндә, ул кеше буларак күңелемә хуш килде. Гадәттә бит аның яшендәгеләр һавалырак була, өйрәтергә яраталар, ә ул андый түгел. Әйткән сүзгә колак сала, сез ничек уйлыйсыз дип, фикерне белешә. Без аңлашып эшләдек. Әле менә күптән түгел «Лаеклы хит» тапшыруында катнаштык. Бер-беребезне сагынганбыз да икән. Яңача «Буран...» миңа игътибарны арттырды дип әйтсәк тә була. Шәхсән үзем интернетта көнтөн утыра торган кеше булмагач, клипның язмышын, аңа нинди фикерләр калдыруларын күзәтеп бармадым. Төрлесе булды, диделәр. Руслан менә шуның кадәр карау җыйды, шуның хәтле фикер калдырганнар дип яза иде, мин алай икән дим инде, тагын нишлим? Руслан тискәре фикерләрне укып кәефе төшмәсә ярар иде дип тә борчылган икән. Сәхнәгә беренче аяк басканда нинди юл сайланган, шуннан барам инде. Акрын гына, бер көйгә. Ошаткан кеше тыңлар, ошатмаганы узып китәр.

:: Заманында зур концертларда чыгыш ясап, соңга таба игътибар кимүне авыр кичерүчеләр бар. Сез ул чорны ничек үткәрдегез?

– Иҗат кайсыдыр арада тукталып торган очракта да, мин бит тик тормадым. Бала үстердем, өй салдым, тагын шөгыльләр таптым. Шулар өстенә җырлаудан та туктамадым. Әгәр инде концерт программасына кертеп тә, кыскартырга туры килде бит әле сезнең чыгышны, дип әйтәләр икән, димәк, мине Аллаһы Тәгалә нәрсәдәндер саклаган дигән нәтиҗә чыгарам. Димәк, миңа ул концертта чыгыш ясарга ярамаган. Кайвакыт концертны кичектерергә туры килә. Шулай кирәк булган, дим. Андый нәрсәләргә бәргәләнгәнем юк. Акча даулаганым, мин бу суммага эшләмим дип тавыш куптарганым да булмады. Мин – бик тыныч кеше.

:: Популярлыкның тагын бер юлы – социаль челтәрләрдә активлык. Сез бу алымны бик кулланмыйсыз кебек? Нәрсә чабудан тота?

– Аның бер сәбәбе – ялкаулыктыр. Контент ясыйм дип, көн-төн социаль челтәрләрдә утыра алмыйм. Зур хезмәт бит ул. Әйтик, менә концертларда башка артистлар белән очрашабыз. Алар гримеркага килеп керү белән эшли башлый. Кая килгән, нинди чара була, ничек прическа ясыйлар, сәхнә нинди – барысын да төшерә, аннары тараталар. Кайвакыт гримерка тулы кеше, ә сөйләшергә беркем дә юк. Барысы да телефонга береккән. «Кара, ничек күңелле сөйләшеп утырабыз», – дип төрттерәм кайчак. Элегрәк без очрашканда аралаша идек. Шул чакларны сагынам. Үзем берәр җиргә чакырылу булсам, телефонны сүндереп куям. Аралашканда, ял иткәндә телефон комачауламаска тиеш. Эш беткәч, юлга чыкканда якыннарыма, кайтырга чыктым, дип хәбәр бирәм.

> Социаль челтәрләрдә актив кешеләргә сокланам, булдыргач, бары тик афәрин генә. Мин – җир кешеседер, күрәсең, виртуаль дөньяга бөтенләй кызыкмыйм. Аннары социаль челтәргә кер юганны, чәй эчкәнне чыгаруның хаҗәтен күрмим. Аны бөтен кеше шулай эшли торгандыр инде. Дөрес, берара бакча хәлләрен төшереп куя башлаган идем, анысы да тукталды. Әйтәм бит, ул эш минеке түгел.

:: Алай да, сорыйк әле: Лилия тормышны ничек алып бара? Кайда эшли, ни белән шөгыльләнә?

– Банкетларга даими чакыралар, иҗат белән тормыш алып барам. Хезмәт кенәгәм әнине карау буенча Пенсия фондына тапшырылган.

:: Җырчылар Казанга тартыла, сез Арчада яшисез. Күчену теләге юкмы?

– Казанга барып кайткан арада гына да алҗыйм. Миңа Арчам, аның һавасы, кешеләре якын. Гәрчә Казанда фатирым булса да, анда яшисем килми. Бәлкем тора-бара фикерем үзгәрер, хәзергә шулай.

:: Бездә иң сүгелә торган өлкә – эстрада. Артистның киеменә дә, аранжировкага да, репертуарга да эләгә. Тәнкыйтьнең кайсылары белән килешәсез, кайсылары белән юк?

– Үзем сүзләргә игътибар итәм. Шигырьдә килешеп бетмәгән җире булса, автор белән сөйләшеп, аны үзгәртерә идем. Аннары көйнең сүз белән тәңгәллегә әһәмиятле. Репертуарым шулай төзелде. Җырларымны мәгънәсез дип әйтеп булмый торгандыр. Ник дигәндә, җыр тәрбияләргә тиеш, дигән кагыйдәгә таянып эш итәм. Педагог булып та эшләгәч, миңа бу бик мөһим. Арча көллиятен тәмамлаган кешенең башта мәктәпләрдә чарлануы табигый инде ул. Дүрт ел укытканнан соң Казан мәдәният институтына укырга кердем дә, аны тәмамлагач, мәктәпкә кире кайтмадым инде. Сәхнәгә дә соңлап чыккан кеше мин, бәлкем шуңа җырга таләбем зурдыр. Ә бит шулай булмаса, истә кала торган җыр тумый. Менә хәзер җырлар истә каламы? Күбесе бер колактан керә, икенчесеннән чыгып китә. Шуңа тәнкыйть белән килешмичә дә булмый. Җырлар бик еш тәкъдим итәләр миңа, юк инде, «электерми», андыйга алынуның файдасы юк. Әле менә шушы көннәрдә Гүзәлия җыр бирде, анда нәрсәдер бар, алынырга була. Чөнки минем өчен җыр яздыру ул – шулкадәр мавыктыргыч процесс, нәкъ менә бала тудырган төсле. Ул – синеке генә. Шуңа күрә кемдер моңарчы башкарган җырларга да алынмыйм. Элеккеге җырларны кабатлап җырлау «перепевка» дип атала. Ул – зур эш түгел. Үз җырыңны булдыру – менә анысы зур эш.

Блиц-сораштыру

– Бәхет – сезнеңчә, нәрсә?
– Максатның теләк белән кушылуын бәхет дип саныйм.
– Хатын-кызга хас булган төп биш сыйфат?
– Эшчәнлек, пөхтәлек, ярата белү, игелеклелек, зыялылык... Алар бик күп, шактыйны санап була.
– Иң яратмаган эш нәрсә?
– Физик эшләрне алсак, савыт-саба юарга яратмыйм. Әмма юылмаган савыт-сабаны төнгә калдырмыйм. Безне, юылмаган савыт сиңа фәкыйрьлек теләп тора, дип өйрәттеләр. Бик яхшы тәрбия чарасы булган ул. Ә ир-ат эшләрен бик яратып башкарам. Шуңа күрә идәнне дә абый белән бергә җәйдек, штукатур-маляр эшләрен әйтеп тә тормыйм инде.
– Соңгы укыган китабыгыз?
– Күбрәк тәрбияви, документаль китаплар укыйм. Соңгысы әни мәхәббәте турында булды. Ул нинди микъдарда булырга тиеш, балага нинди дәрәҗәдә ирек бирергә ярый – бу минем өчен әһәмиятле иде.
– Тормыш девизыгыз?
– Мин шулай телим. Шулай диям дә, хәзерге мизгелдә нәрсә телим – шуны күз алдына китерәм.

:: Үзешчәннәр белән профессионалларның аермасы бетте. Эстрада җиңеләйде. Бу киләчәктә ничек чагылыш табар?
– Без сәхнәгә чыкканда, ул әле буй җитмәслек бер үр иде. Хәзер анда теләсә кем менә ала. Акчасы булса, теләсә кем җырлый ала. Тавышың бармы синең, юкмы – анысы мөһим түгел. Шуңа күрә эстраданың кызыгы бетте. Халыкны да шаккатырып булмый инде. Хәер, бу хәлләр өндә барамы, дип шаккатып торам кайвакыт. Киләчәккә бөтен җыр да барып җитмәячәк, билгеле. Ә менә хәзер барган хәлләр бик кызганыч. Җәүһәр дәрәҗәсендәге җырларны бозуны кабул итеп булмый. Тоталар да, халык җырын заманчалатабыз дип, джаз яки башка формада башкаралар. Кайбер фестивальләр кем начаррак җырлый конкурсын хәтерләтә кайчак. Хәер, бу – минем фикерем, бәлкем ул дөрес тә түгелдер. Шул ук «Үзгәреш җиле»нә зал тутырып халык килә бит. Димәк, ул аларга ошый. Ошагач, яшәргә хакы бар.

:: Сезнең репертуар мәгънәле җырлардан тора. «Хәерле юл тели һәйкәлләр», «Буран дулый», «Мәхәббәт шушыдыр», «Ялгышканмын». Ничек уйлыйсыз, ретро җырларны заманчалаштырырга кирәкме?
– Бер җыр белән тәҗрибә ясап карау ул әле бөтен җырларны да заманга яраклаштырырга кирәк дигән сүз түгел. Ул аннан соң күңел кайтаргыч нәрсәгә әвереләчәк. «Буран дулый» – Роберт Миңнуллин сүзләренә язылган җыр. Аңа Руслан белән алынганчы, мин әлеге җыр көенең авторы Оскар Усманов белән дә киңәшләштем. Ул: «Бик сак булырга кирәк, халык башка яңгырашта кабул итмәскә мөмкин», – дип әйтте. Чыннан да шулай. Минем репертуарымда ул элеккеге көенчә калачак. Каядыр Руслан белән чыгыш ясарга чакыралар икән, анда яңача башкарачакбыз. Сез санап киткән җырларны халык үзе күтәрде. Радиога шалтыратып, шул җырны яңгырата алмассызмы икән, дип сорыйлар иде. Хәзер җырчы акча түләп ротациягә бирә дә, ул сәгать саен яңгырый. Хәзер тыңлаучы фикере ул кадәр мөһим түгел инде.

:: Нәселдә җырлаучылар тагын бармы?
– Әнинең бертуган сеңлесенең кызы Алидәнең үз вакытында җырчы буласы килеп йөрде. Мин дә аның белән шөгыльләндем, композитор Гүзәлия җыр да язды. Шуннан икебез дә шаккатып тыңладык, нәкъ минем кебек, минем тавыш белән җырлый икән. «Алидә, кызым, син җырла, ләкин башка һөнәр дә үзләштер әле», – дидем. Чөнки эстрадага икенче Хәмитова кирәкми. Киңәшкә колак салды, үз һөнәрен бик ярата. Нәселдә башка җырчы юк дисәң дә була. Игезәк сыңарым Алия дә башка өлкәдә эшли. Ә бу сәләт миңа, бәлкем әтидән күчкәндер. Ул бик матур җырлый торган булган, гармун уйнаган. Без өч бала аны бик хәтерләмибез дә инде, әти вафат булганда, мәсәлән, без – игезәкләргә 5 яшь кенә булган.

:: Улыгыз нәрсәләр белән кызыксына?
– Программист булырга укый, гитарада уйнарга өйрәнә.

:: «Сольный» концерт күтәргәме инде сездән?
– Иртәгә нәрсә буласын белми торган заманда яшибез бит. Син беренче шалтыратканда да мине «скорый» белән алып киткәннәр иде. Егылып, кабыргамны имгәттем. Винарис юбилеена да бара алмам дигән идем әле. Ярый барганмын, кияүгә чыкмыйча кала идем (*көлә*). Булыр дип ышанып яшик.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Мәҗбүри ассимиляциядән исән калган соңгы милләттәшләребезне сыендырган татар резервациясе. Илләр, халыкларны бер түбә астына куып кертеп стройга тезгән, бер тел, бер мәдәниятне генә гамәлгә куеп маташкан Дөньяви хөкүмәт. Танымаслык булып үзгәргән табигать. Бу – булуы мөмкин, тик булмавы мең кат хәерле киләчәк... Антиутопия элементлары кергән әлеге әсәр килер дәверләрнең үтә дә хәвефле булу ихтималын искәртә. Институттагы серле лаборатория вакыт аша үтү мөмкинлеге тудырып кына калмый, повестьның төп герое Зөфәргә, 95 ел вакыт үткәннән соң яралачак вазгыятьне, үз туган авылы мисалында, барып күреп кайтуны да чынга ашыра. Укучыга тәкъдим ителгән кыска өзектә Зөфәрнең киләчәк кешесе – яңа гүзәл танышы Алинә белән корган әңгәмәләре, егеттә уянган хисләр, аларның яңа көрәшүгә өмет тотып хушлашуы бәян ителә.

Якутлар табыладыр вакыт белән,
Вакытлар табылмыйдыр якут белән.
Габделҗаббар Кандалый

O tempore, o mores!
(Вакытлар, тәртипләр, диген...)
Борынгы латин әйтеме

...Әңгәмә икесе дә белгән телдә барып, кызга җавап шул телдә бирелсә дә, үзе әйткән соңгы сүз егетнең колагында татарча да яңгырады. Һәм ул үзе дә абайламастан, таныш җыр сүзләре искә төшеп, татарча сөйләп китте:

– Күптән инде, күптән очрашкан юк. Хәтерлимсез бергә чакларны...

– Сез кайсы телдә сөйлисез? – Кыз, сәерсенеп, Зөфәргә карады.

– Бабаларыбыз телендә, Алинә, татар телендә.

– Ә сез аны каян беләсез?

НАИЛ ШӘРИФУЛЛИН

ЯКУТЛАРГА КИТКӘН ВАКЫТЛАР

(ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕК)

Сорау кунак егетен инде гаҗәпләндерми иде. Әңгәмәдәше телне белсә, һич югы аңласа, ихтимал, гаҗәпләнер сәбәп булыр да иде. Шулай да аралашуның үзе теләгән якка керүенә ул сөенде.

– Без – яшьтәшләр. «Син»гә күчсәк яхшырак булмасмы? – Зөфәргә шушы минутларда элекке, монда килгәннән соң югалып, каядыр китеп торган көләчлек, ниһаять, киредән әйләнеп кайтты. Ул соклану һәм дә елмаю тулы күзләре белән Алинәгә текәлеп һәм тутырып карый алды.

– Мин риза. – Кыз, аның карашыннан аз гына читенсенгәндәй итсә дә, аска төшергән озын керфекләрен кире күтәреп, шулай диде. – Телне белүең каян?

– Балачактан ук беләм. Без – татар кавеменнән, үз халкыбызның телен дә, тарихын да, мәдәниятен дә белергә тиешбез дип уйлыйм. – Зөфәр, битлеген әлегә салмаган булса да, үзенең «резервация вәкиле» икәнен әйтеп, яңадан катлы-катлы алдашуларга кереп китмәскә карар кылган иде. Кызның әтисе алдында ул әле дә кыенлык сизә иде. Алдашу кайсы дәвердә дә алдашу инде. Алинәгә ачыласы, үзенең каян һәм нинди максатлар белән килеп чыкканын белдерәсе килү теләге көчәя генә барды.

– Минем дә танышларым арасында татарчаны белгән бер кеше бар. Тик аның очрагы аерым. Ләкин башка яктан алганда, инде беркем дә сөйләшмәгән телне белү артык хаҗәт микән соң? Латин телен дә махсус өйрәнгән кеше юк ич, медицинада кулланылса да. Аерым сүзләр, терминнар өчен генә тотыла.

– Телләр белү файдага гына. Күбрәк тел белгән саен яхшырак. Үз туган телеңне белми яшәү кешене гел дә бизәми, дигән фикердә мин. Аны өйрәнүгә, телнең кабат кулланышка кайтырына, тулы канлы тел булырына өмет арта...

– Хыял белән яшәгән кешеләр ошый миңа. – Кыз, кояштай елмаеп, Зөфәргә карады. Чыннан да кояш кебек иде ул: ак чәчәкләр сибелгән сары күлмәк, саргылт-көрән чәч, күз явын ала торган мөлаемлык. – Тик, чынбарлыкка кайтканда, без әле сөйләшеп барган тел дә тагын берничә дистә елдан калмаячак, бетәчәк. Глобализациянең яңа – өченче этабына кереп барабыз.

Егет үзе өчен яңа, әле юньләп таныш та булмаган чынбарлыкта глобализация ише сүзне ишетермен дип уйламаган иде. Бигрәк тә шундый чибәр, гүзәл буй-сынлы кыз авызыннан. Егерменче гасырда яралган, егерме бердә дәвам иткән чирнең егерме икенче гасырда да яшәвен чамалавы авыр булмаса да. Кызык, аның өченче этабы нидән гыйбарәт икән?

– Глобализация – байлыкка, комфортка омтылудан туган, кеше үзе, аның мин-минлеге барлыкка китергән продукт. Җимергеч продукт. Ул туфан булып күпме мәдәниятләр, телләр өстеннән узды. Глобализациянең җан дуслары – карунлык белән эгоизм ничә мең еллар һич бер кыерсыту күрмәгән, бәлаләрсез яшәгән күпме җан ияләрен, үсемлекләрне мәңгелеккә озатты... – Зөфәр кызыбрак китте.

– Табигать артык тырышкан шул, кирәген дә, бик үк кирәк булмаганын да яраткан. Бөҗәкләрнең генә дә миллионнан артык төре булган, дип укыган идем берсендә. Шул тиклем күптөрлелек күзәтелгәч, кемнәрдер, нәрсәләрдер юкка чыкмый калмый инде. Көндәшлек, яшәү пространствосы өчен көрәш – эволюциянең аерылгысыз өлеше бит.

– Глобализациянең эволюциягә катнашы юк, Алинә. Хәтта әйтер идем, ул нәмәрсә – эволюциянең кан дошманы. Табигать яратканны табигать үзе генә юк итәргә хокуклы: бер генә үлән дә, бер генә чикерткә дә, суалчан да кемнеңдер комагай хаҗәте үтәлсен, дип илле, йөз, йөз илле ел эчендә юкка чыгарга тиеш түгел. Тел, гореф-гадәтләр хакында әйткән дә юк. – Зөфәрнең киләчәкнең шушы якты карашлы гүзәл кызының үз инанулары белән килешүен, аны аңлавын бик тели иде. Ләкин Алинә, күрәмсең, үз заманын ничек бар, шулай кабул итә, барын да дөрескә саный, бирешергә исәпләми.

– Син әйткән закон үтәлсә, динозаврлар бүген дә безнең котны алып янәшә яшәр иде. – Алинә, күзләрендә шаян очкыннар чыгарып, чын кызларча рәхәт итеп, чыркылдап көлеп куйды.

– Динозаврлар табигый бәла-казалар аркасында юкка чыккан. Ә үсемлекләр белән бөҗәкләр, кошлар белән хайваннар кешенең үзе хакында гына кайгыртуы сәбәпле, бер-бер артлы югала. Кеше затының алай кылануы бер дә дөрес түгел.

– Син хаклыдыр да, бәлки. Шулай да ниндидер елан-хәшәрәтләрнең җирдә калуында ни файда? Әле агулы да булсалар?

– Табигать барлыкка китергән икән, димәк, алар кирәк. Кеше ашкынып, шикле технологияләр кулланып, алны-артны карамый хуҗалык итә башлаганчы алар ничә мең, миллион еллар буе яшәгән. Беркемгә дә комачауламаган. Дөньяда – һәркемнең үз урыны, үз ризыгы...

– Ә классик әйткән «Табигать гыйбадәтханә түгел, остаханә...» дигән сүзләр?..

– Ике гасыр элек яраган ул шигарь искерде генә түгел, асылын да үзгәртте. Егерменче гасырдан башлап кешеләр, акыллары булса, табигатьтә нәкъ менә гыйбадәтханә күрә башларга тиешләр иде. Күрмәделәр, аны төрлечә басымчаклауны дәвам иттеләр. Нәтиҗәләрен бүген сукыр кеше дә күрә булыр. Тышкы дөнья, табигать барлы-юклы йөз, ике йөз ел эчендә безгә терәк булудан туктады. Ул хәзер безгә каршы. Чөнки без аның өметен акламадык: кеше, үзен акыллырак санап, үзен бар иткән тирәлек белән бөтенләй исәпләшми башлады. Ә бит безне урап алган дөнья биосистеманы акылы, зиһене булган тере организм, диләр. Һәм ул сакланырга гына түгел, һөҗүмгә күчәргә дә мәҗбүр. Мәсәлән, шул ук глобаль җылынуны эшкә җигеп. Яисә яңа вируслар тудырып – без юньләп белмәгән микродөнья тулысынча аның карамагында. Тышкы тирәлек, табигать бездән акыллырак һәм дә көчлерәк. Ул бездән котылу ягын караячак һәм котылачак та.

– Нинди куркыныч фаразлар. Тик бөтенләй килешмәү дә мөмкин түгел. Глобаль җылыну китергән бәла-казалардан һәммәбез дә хәбәрдар анысы. Тик ул күренештә элегрәк яшәгән буыннар күбрәк гаепле түгелме икән? Синең мантыйкны дәвам иткәндә, вазгыятьне башкача да аңлатып була: кешелек, элек үк – углеводородларны күпләп яккан чорларда ук, үзен юкка чыгарачак программаны эшләтеп җибәргән дә пассив күзәтче ролендә шул процессны күзәтеп тора.

Дәвамы киләсе санда >

ӘБИТУРИЕНТ

Әнисе:

– Улым, быел мәктәпне тәмамлыйсың, кая укырга керерсең икән?

– Табиб буласым килә, әни.

– Медицинаның бит аның төрле юнәлешләре бар, кайсы факультетка кызыгасың?

– Менә кинода күрсәтәләр бит, үлем хәлендәге кешене хастаханәгә алып киләләр дә, табиб тиз генә аңа ярдәм итә башлый. Нинди табиб ул?

Әбисе:

– Димәк, сиңа ГИТИСка барырга кирәк, улым.

Әз-мәз мәзәк

– Лилия, ни хәлең бар?

– Хастаханәдән кайтып килəм. Ай буе урын өстендә яттым.

– Зур сынау узгансың.

– Нинди сынау! Йокымны туйдырдым рәхәтләнеп! Ә өйдә өч бала көтә...

* * *

– Кем син?

– Мин – франчайзи һәм коуч.

– Ну, әйтсәң килмәсә әйтмә.

* * *

Ирең синең белән аерылганнан соң кинәт баеп китсә, иң көнчелсезе шул.

* * *

– Кичә кайда идең?

– Фәлсәфә белән шөгыльләндем.

– Сократ? Платонны укыдыңмы?

– Юк, бераз утырып алдык.

Сканворд җаваплары

Горизонталь:ияр, Пепе, сары, Ык, Акура, риба, тары, арт, нут, Хәбил, шпана, Асса, алаша, он, Рим, Дивана, анфас, фал, Әләзән, Моабит, автор, Рамил, Ра, Явыз, уңа, шәм, тәм, Штерн, Ла, ала, ба, гаепле, төн, Урсал, уян, Алия, го, Усов.

Вертикаль: арка, Ихсанова, бәс, абага, оят, Сәрвәр, ятлау, ым, Ту, яран, Фәез, Бөреле, аркан, Шанс, пычкы, Фәрит, яу, Адана, егылу, аптыраш, ил, Мура, Яго, Карпов, Миңнеханов, тана, Ола, ял, Наратбаш, әл, тәмлетамак.

«КАРПАТКА»
һәм
«КАРНИКА»
токымлы 4әр
рамлы умарталар
сатам.
Бал корты
личинкалары – 2–3 рам.
Бал икмәге – 1 рам.
+7 96 55 99 88 67
+7 96 25 61 60 93
Реклама



Беләсең килсә...

1 Шагыйрь образы турында ул болай дип язган: «Ул дөньяның асылын ачмак була, ә асылы аның кеше җаны».

а) Мәдәррис Әгъләмов;

б) Марсель Галиев;

в) Роберт Әхмәтҗанов.

2 Юпитер планетасының бер иярченe шушы исемне йөртә:

а) Европа;

б) Азия;

в) Африка.

3 Ресторанга иң күбе ничә Мишлен йолдызы бирелергә мөмкин?

а) 3;

б) 5;

в) 7.

4 Лобстерларның миләре кайда урнашкан?

а) аякта;

б) койрыкта;

в) тамакта.

Җаваплар: 1. а); 2. а); 3. а); 4. в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15281 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 237

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+